1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

16+ татмедиа

# Шәһри КАЗАН

Пәнҗешәмбе | 17.07.2014 | № 78 (5404)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ



ФИКЕР 5 БИТ

АВЫЛ БЕТКӘНГӘ ТӘМӘКЕ ТАРТУ ГАЕПЛЕ – МАРАТ КӘБИРОВ ЯҢА ЗАКОННАРНЫ ӨЙРӘНӘ

ФАҖИГА 6-7 БИТ

БЕЗНЕҢ БАЛАЛАРНЫ КЕМ САКЛАРГА ТИЕШ? КҮПЧЕЛЕК САБЫЙЛАР ФАҖИГАСЕНДӘ ӘТИ-ӘНИЛӘРНЕ ГАЕПЛИ

16 БИТ

БАШКАЛАГА ДӨНЬЯНЫҢ 102 ИЛЕННӘН ЗАМАНА МУШКЕТЕРЛАРЫ ҖЫЕЛДЫ

# КАЗАН ВУЗЛАРЫ НИНДИ ТОРАК ТӘКЪДИМ ИТӘ



ДАМИР БӘДРИЕВ ФОТОСЫ

**«ШК» журналисты тулай торакларны барлады**

Теманың дәвамы → 8 БИТТӘ

## БАШКАЛАДА

Казандагы Республика клиник онкология диспансеры базасындагы «Ядерная медицина» үзәгендә иртәгә радионуклид терапиясе бүлеге ачыла. Радионуклид терапиясе өчен өстенлекле юнәлеш – калкансыман биз яман шеше, зоб авырулары. Дәвалау биредә тәүлек әйләнәсе медицина персоналы күзәтүе астында алып барыла. Бүлек аена 32 пациентны кабул итәргә мөмкин.

Казан метросында өч көн дәвамында барлык системаларның куркынычсызлыгы тикшерелә. Эш төн уртасында башлана һәм иртәнге 5тә тәмамлана. «Метроэлектротранс» предприятиесе генераль директоры Әсфән Галәвов сүзләренчә, профилактика максатыннан, көтелмәгән хәлләр очрагына дип, штаттагы хезмәткәрләрдән 40 кешелек бригада булдырылган.

Казан мэры Илсур Метшин Россия субъектлары башкалалары башлыкларының июль рейтингы башында тора. Ул «Халык рейтингы» лидеры дип (78 балл) табылган. Икенче һәм өченче баскычта – Краснодар һәм Мәскәү башлыклары - Владимир Евланов һәм Сергей Собянин (76 һәм 74 балл).

РЕКЛАМА

ЛУЧШИЕ САНАТОРИИ, ДОМА И БАЗЫ ОТДЫХА ТАТАРСТАНА, МАРИЙ ЭЛ, ЧУВАШИИ

Санаторий «Васильевский»
бальнео-климатический курорт широкого профиля
Заезды 7/14/21 день, на автобусе: 29.07, 12.08
Цена за 1 сутки от 2000 руб.
АКЦИЯ*: ПЕНСИОНЕРАМ 14 суток – от 21.000 руб.
*условия по телефону 253-20-30

АКЦИЯ! ВСЕМ ПОДАРОК 3 ДНЯ! в Санаторий «Каменная речка» (при покупке путёвки на 8 дней)
Санаторий находится в Марий Эл, на реке Малая Кокшага, в 130 км от Казани.
2,3,4-х местные номера, питание 5 раз, лечебница.
Рекомендуем для семейного отдыха с детьми.
Заезды на автобусе из Казани: 16.07, 26.07, 07.08, 17.08.
Цена за 8 (11) дней от 9 680/10 450 руб (с леч.)

Санаторий «Кленовая гора»
бальнео-грязевой климатический курорт широкого профиля
Заезды 7/10/21 суток, на автобусе: 23.07, 03.08, 14.08, 25.08, 08.09
Цена за 1 сутки 1330/1730 руб.
АКЦИЯ*: ПЕНСИОНЕРАМ 10 суток – от 11.190 руб.
*условия по телефону 253-20-30

Объединение ТУРИСТ
ТУРИСТИЧЕСКАЯ КОМПАНИЯ
253-20-30 (многоканальный)
Петербургская,55А
Чистопольская,5
Зорге,39А

«ШӘҺРИ КАЗАН»ДА БЕРГӘ КАЙНЫЙК! ТЕЛЕФОННАРЫБЫЗ (843) 562-50-07 (ФАКС), 562-50-12



«Мәскәүдәге фаҗигагә бәйле рәвештә Казан метросында ниндидер өстәмә чаралар күрү зарурлыгы юк, чөнки, бәхеткә, бездә бар да әйбәт»

**ӘСФӘН ГАЛӘВОВ,** «Метроэлектротранс» предприятиесе директоры

# Эшләгән эш күренә

**СӘЛАМӘТЛЕК**

Бүген шәһәр сырхауханәләрендәге шартлар көннән-көн күзгә күренеп яхшыра бара. Бу сүзләрне күптән түгел генә ремонт эшләре төгәлләнгән 7 нче балалар клиник хастаханәсен карарга баргач, Казан мэры Илсур Метшин әйтте.



Чыннан да, әле моннан берничә еллар элек кенә сәламәтлек саклау учреждениеләренең күпчелеге ремонт таләп итә, ә аны башкарып чыгу шәһәр бюджеты өчен күтәрә алмаслык йөк сыман иде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм кайбер депутатларның тырышлыгы белән әлеге мәсьәлә әкренләп хәл ителде дияргә була.

Айдаров урамында урнашкан 7 нче балалар хастаханәсе инде 1970 елда сафка бастырылган булуга карамастан, 2010 елга кадәр бер тапкыр да ремонт күрмәгән дисәң дә була. Дөрес, 2008 елда хастаханәнең стационар өлешенә капиталь ремонт ясау өчен шәһәр бюджетыннан 20 млн сум акча күчерелгән булган, ләкин ул барлык проблемаларны да хәл итәргә җитмәгән. Татарстан Дәүләт Советы депутаты Николай Рыбушкин, артыннан йөреп, Президент аркылы республика бюджетыннан ремонт өчен 45 млн сум акча күчертүгә ирешкән. Әлеге акчага стационарга капиталь ремонт эшләнгән, Челюскин урамында урнашкан беренче сырхауханә бүлегендә төзекләндерү эшләре башкарылган, яңа җиһазлар һәм медицина кирәк-яраклары сатып алынган.

– Элеккеге белән чагыштырганда җир белән күк арасы бит монда, - диде шәһәр башлыгы сырхауханә ишегеннән килеп керешкә. – Ремонттан соң яктырып, күпкә матураеп киткән.

Сырхауханәгә килеп керүгә табибка язылу өчен махсус терминал куелган. Биредә эшләүче хезмәткәрләр әйтүенчә, электрон чиратка язылу мөмкинлеге аларның эшен күпкә җиңеләйткән, табибка күренергә килүчеләрнең дә 97 проценты терминал аша язылуны өстенрәк күрә икән.

Баш табиб урынбасары Наталья Дружинина әйтүенчә, 7 нче хастаханә республикада иң көчле аллергология һәм пульмонология үзәге булып санала. Шулай ук ул аллергия белән авыручы балаларның саны көннән-көн арта баруын да ассызыклап үтте.

– Ләкин бездәге заманча җиһазлар авыруны башлангыч чорында ук ачыклау мөмкинлеге бирә. Авыруны никадәр алданрак дәваларга керешсәң, шулкадәр яхшырак бит, - диде ул. - Бездәге галокомплекс дип аталган дәвалау курсы да бик яхшы нәтиҗәләр бирә. Мондый тоз белән дәвалау кабинетлары республикада бары тик безнең сырхауханәдә генә.

– Әгәр гаиләдә аш өстәлендә шифалы су урынына «Кока-Кола» һәм чипсылар торса, бернинди дә медицина ярдәм итә алмый. Иң мөһиме – сәламәт яшәү рәвеше, – диде Илсур Метшин.

# «TURKVIZION» Казанда уза



**Алинә Шәрипҗанова фестивальдә дүртенче урын алган иде.**

Казанда бүген «TURKVIZION» бәйгесен тәкъдим итү булачак. II Халыкара телевизион җыр бәйгесенең презентациясе «Казан» милли мәдәни үзәгендә кичке 19.00 сәгатьтә башлана. Бу төрки дөнья өчен «Евровидение» белән тиңләшерлек бәйге.

Төрки дөньяның иң яхшы тавышларын ишетү хокукы Казанга узган ел ТЮРКСОЙ халыкара оешмасы карары белән бирелгән иде. Казан - 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы, димәк, «TURKVIZION» да бездә уза. Казан әлеге бәйгенең ярымфинал һәм финал бәйгеләрен уздырачак. Әзәрбайҗан, Төркия, Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Гыйрак, Кипр, Молдова, Башкортстан, Кырым телеканаллары җитәкчелеге һәм төшерү төркемнәре дә катнашачак бу чара кысаларында аның төп оештыручысы – TMB TV музыкаль телеканалы һәм халыкара телеканаллар арасында танталаны рәвештә килешү дә төзеләчәк. Алга таба ул телеканаллар урыннарда сайлап алу турлары уздырып, бәйгеләрне - 19 ноябрь (ярымфинал) һәм 21 ноябрь (финал) туры эфирда күрсәтәчәкләр. Төрки дөньяның заманча эстрада музыка сәнгатен популярлаштыру, популяр һәм халык музыкасы өлкәсендә талантларга ярдәм күрсәтү, халык традицияләрен саклау һәм үстерү, төрки дөнья илләре һәм халыклары арасында хезмәттәшлекне ныгыту кебек изге максатларны күздә тота бу чара.

Хәтерләсәгез, Казан җырчысы Алинә Шәрипҗанова (Алиша) узган ел Төркиядә беренче тапкыр уздырылган әлеге бәйгедә Татарстан данын яклап, ярымфиналда - I, бәйгенең финалында исә дүртенче урынга лаек булган иде. Төрки дөньяның иң яхшы тавышы исеме өчен 24 илдән сайлап алу турларын үткән җиңүчеләр көч сынашты анда. Алинәне исә утызлап татар җырчысы арасыннан сайлап җибәргәннәр иде.

# Шәһәр кәефе



**ФӘРИТ НУРМӨХӘММӘТОВ,** журналист:

*– Казан – борынгы шәһәр, урамнары тар, йортлары тыгыз урнашкан дияргә дә була. Метро бик кирәк иде, шөкер, булды, әмма Казан өчен станцияләре азрак әле. Кварталда яшәгәнлектән, ул якларда да булса иде дип телим.*



**ЗӨЛХИЯ НӘКИПОВА,** пенсионер:

*– Иптәш хатын белән Казан үзәгенә барып киләсе иттек әле. Бакчада ятып, шәһәргә чыгарга да вакыт юк. Кыярлар өлгерә, чиялә пешә – эш тә эш. Көннәре дә бөркүгә китте әле, җитмәсә. Гомумән алганда, сәламәтлек Аллага шөкер, пенсия килеп тора, бар да яхшы.*



**АЙРАТ НИЗАМЕТДИНОВ,** шәхси эшмәкәр:

*– Үземә эшләгәч, гел юлда уза минем гомер. Менә хәзер дә үзбушаткычыма чүп-чар төягәннәрен көтеп торам. Казанның чокыр-чакырлы юлларын сүгә-сүгә, метрода йөрүчеләргә кызыгып йөрим. Минем өчен Зиннәтулла Биләлетдиновның «Ак Барс»ка кире кайту хәбәре соңгы көннәрнең төп шатлыгы булды.*



**АЛЬБИНА ГАЙНЕТДИНОВА,** студент:

*– Авиатөзелеш районында яши торган дәү әниемә барышым. Метрода йөрим, ара ерак булса да, укудан чыккач та ә дигәнче барып җитәм мин анда, автобуста тыгылып йөрисе юк. Энергетика университеты каршындагы көллияттә укыйм, өченче курска күчтем.*



**ӘНӘС БИКБОВ,** пенсионер:

*– Таяклы бабай булсам да, футбол белән хоккейны карап барырга тырышам, бу арада чемпионатны карадым. Җәй көне хәбәрләргә бик вакыт калмый, әби вак-тояк эшне таба да тора. Менә әле метрога гаҗәпләнеп карап торам, бер минутка әллә ничә кеше кереп, чыгып йөри шунда.*



**РЕГИНА КӘЛИМУЛЛИНА,** промоутер:

*– Җәем эшләп үтә. Студентларның каникуллары бит, мин ял итмим, промоутер булып эшлим менә. Уку йорты өй янында гына урнашканга, транспорттан сирәк файдаланам. Метрога да әллә нигә бер генә төшәм. Шәһәр буйлап йөрергә туры килсә, һичшиксез, шуның белән генә йөрер идем анысы, ошый ул миңа.*

Агымдагы елда республикада күпфатирлы торак йортларны капиталь ремонтлау өчен каралган 4,68 миллиард сумнан 3,43 миллиард сумлык эш башкарылган

4,68 млрд.

3,43 млрд.

# «ҖӘЙ БЕЗГӘ КИРТӘ ТҮГЕЛ»

Республиканың Премьер-министры урынбасары, «Бердәм Россия» партиясенең сайлау алды штабы җитәкчесе Юрий Камалтынов Үзәк сайлау комиссиясенә Дәүләт Советына депутатлыкка кандидатлар исемлеген тапшырганнан соң, партия сайлау кампаниясенең беренче этабын төгәлләде дип белдерде.



Эльза Хамматова

– Без исемлекне бирү буенча ашыкмадык, чөнки комиссиянең безгә карата претензияләре булмасын дип, барлык кирәкле материалларны да җиренә җиткереп әзерләргә тырыштык. Үзәк комиссия безнең кандидатларны теркәгәннән соң, җиң сызганып төп эшкә күчәбез, – диде ул «Бердәм Россия» партиясенең киләсе сайлаулар алдыннан куелган максат һәм бурычлары буенча уздырылган матбугат конференциясендә.

Төп эш дигәне – бөтен Татарстан территориясе буйлап халык арасында агитация чаралары алып бару. Киләсе атнадан «Бердәм Россия» активы кандидатлар һәм гамәлдәге депутатлар белән берлектә урыннарда актив эш башлап җибәрәчәк. Юрий Камалтынов инде уздырыласы төп чараларның графигы да әзер булуын әйтеп үтте. Дөрес, сайлау алды агитациясе җәй вакытына – бар халык бакчада яисә ял иткән чакка туры килә.

– Җәйге сезонның үзенең плюслары да, минуслары да бар. Ләкин ул партия өчен әллә ни проблема тудырмый, чөнки халык белән аралашу ел әйләнәсендә алып барыла – партия вәкилләре халыкны борчыган проблемалар белән танышып, аларны хәл итү буенча эш алып бара, – дип белдерде штаб җитәкчесе. – Аның каравы, халык белән аралашу җиңеләячәк, чөнки рәхәтләнеп йортлар янындагы ишегалларында җыелып сөйләшеп булачак. Бу дүрт стена арасында аралашуга караганда күпкә яхшырак дип саныйм.

Билгеле булганча, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Бердәм Россия» партиясенең депутатлыкка кандидатлар исемлегендә беренче булып тора. Юрий Камалтынов әйтүенчә, бу Президентның партиягә ышанычы зур булуын күрсәтә, ә партия әлеге ышанычны һичшиксез акларга тиеш. Шул ук вакытта ул Президентның кандидатлар исемлегендә булуы партия өчен саллы ярдәм икәнлеген дә ассызыклап үтте, чөнки Рөстәм Миңнеханов җитәкчеләр рейтингының югары баскычында тора, халык арасында да дәрәҗәсе зур.



Юрий Камалтынов партиянең сайлау алды стратегиясе тулысынча әзер, дип белдерде.

Гомумән алганда, Дәүләт Советына депутатлыкка кандидатлар исемлегендә «Бердәм Россия»дән 56 кеше. Татарстанның Дәүләт Советы сәркатибе, партиянең штаб җитәкчесе урынбасары Лилия Маврина әйтүенчә, башта праймеризда, ягъни партия эчендә тавыш биреп кандидатлар сайлауда 157 кеше катнашкан. Праймериздан соң кандидатларның күпме тавыш җыюына карап рейтинг булдырылган. Күпмедер вакыттан соң катнашучыларның башта – икесе, аннан 18 кеше кандидатураларын исемлектән алуны сорап гариза язган. Исемлекнең сирәгәюе рейтинг нәтиҗәләренә әз генә дә йогынты ясамаган.

– Исемлектәге бер генә кандидат та өскә дә менмәде, аска да төшмәде, - дип ышандырды Лилия Маврина. – Аларның күбесенең беренче генә сайлануы, аларның барысы да – шәхес булып җитлеккән кызыклы шәхесләр.

# СҮЗЕҢ БУЛСА, «ХАЛЫК КОНТРОЛЕ»НӘ ҖИТКЕР

**ҖӘМГЫЯТЬ.** Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Министрлар Кабинетында узган киңәшмәләрнең берсендә совет заманнарында халык контроле структурасының нәтиҗәле эшләгәнлеген искәртеп, аны кабат гамәлгә кертүнең мөһимлеген әйткән иде.



Дамир Бәдриев

2012 елның апреленнән Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында «Халык контроле» («Народный контроль») адресы эшли дә башлады. «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат челтәреннән файдаланучылар белән элемтәләрне координацияләү бүлеге җитәкчесе Рөстәм Низамиев сөйләгәнчә, җәмәгатьчелектән инде 25056 хәбәр кергән. Шуларның 15298е уңай чишелеш тапкан, 991 хәбәр буенча эш бара, 4277се эш планына кертелгән. Мәсәлән, башкаланың Красная Позиция, А.Кутуй, Г.Коләхмәтов урамнарында юлларның начарлыгы тәнкыйтьләнгән булган. «Халык контроле»ннән күрсәтмә килеп төшүгә үк, әлеге юллар төзекләндерелгән.

– Казанда светофорларның төзексезлегә турында хәбәр керсә, аны кыска вакыт эчендә төзәтәләр. Чаллы шәһәренең Сөембикә проспектындагы ватык светофорны бер ел инде төзәтүче юк. Чаллыдан шушы хакта кергән хәбәр һаман «башкарылмаган» мөрәҗәгатьләр исемлегендә тора. Зеленый борда күл буйларының чүплеккә әверелеп баруы турында хәбәр алынган иде. Лаеш районы муниципаль берәмлеге җыештыру чаралары күрде. Әлеге мәсьәләне күтәргән кеше соңыннан «Халык контроле» нә рәхмәт юллады, – диде Рөстәм Низамиев.

## БЕЛЕШМӘ

«Халык контроле»ндә Казаннан 6418 хәбәр теркәлгән, шуның 3108е хәл ителгән.

Мамадышта Кирпичная урамында юл өслегенең ватылып беткәнлеге турында хәбәр иткән булганнар, файдасы тигән – хәзер ул юл төзек. Нурлатта бер ишегалдының җимереклеге турында хәбәр яңгырауга ук, биредә берне генә түгел, ә 50 ишегалдын төзекләндерү буенча җирле программа кабул ителгән. «Халык контроле»нә Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Кукмара, Яшел Үзән, Нурлат, Биектау, Лаеш һәм Чистай муниципаль берәмлекләреннән хәбәрләр күп керә, әмма аларда күпчелек мәсьәләләр уңай чишелеш таба бара. «Министрлыклар һәм ведомстволар хәбәрләр белән танышып тора, мәгълүмат Татарстан Президентына да җиткерелә», – диде Рөстәм Низамиев.



Рәмис Латыйповтан

АТНАЛЫК КҮЗӘТҮ

ПӘНҖЕШӘМБЕДӘН-ПӘНҖЕШӘМБЕГӘ

# «СУГЫШЛАР ГЫНА БУЛМАСЫН»

Безнең әби-бабайларның теләкләр теләгән чакта бик еш әйтелә торган сүзе бу. Өлкәннәрдән бу теләк яшь буынга да күчкән. Кайберәүләрдә каһкаһәле елмаю да тудыра. Әмма сугыш дигән афәт юк сүз түгел, була калса, һәркемгә өлеше җитә икәнен бүген үзебез күреп торабыз. Украинадан 128 качак Чаллыга килеп егылдылар. Туган җирләреннән кубарылып, безнең якларга килгән кешеләр арасында 59 бала да бар. Без кинофильмнардан гына карап белгән шушындый вакыйгаларның, кулларына балаларын күтәреп, күзләре кая карый, шунда чыгып киткән качакларның безнең заманда да булачагын кем уйлаган диген?

Татарстан буенча эчке эшләр министры Артем Хохоринның бу атнадагы чыгышын тыңласаң, бездә дә сугыш бара икән дип уйларга була. Быел 156 кешене үтергәннәр, 325 кешегә тән җәрәхәтләре ясаганнар, аларның 65 е вафат – шулай итеп, менә сиңа өзелгән 221 гомер. Башка елларга караганда, башка төбәкләр белән чагыштырганда үтерүләр саны азрак диләр, бәлки, чагыштырмача дөрестән дә азрактыр. Әмма еллык хисапларны карап утырсаң, күңелне бер дә оптимистик хисләр биләми. Бу атнада тагын бер кеше үтерүче гомерлеккә ирегеннән мәхрүм ителде. Универсиаданың соңгы көнендә Дәрвишләр бистәсендә үзе белән очрашып йөргән хатынны һәм аның әти-әнисен үтергән Руслан Хәлимовны гомерлеккә Оренбургның Соль-Илецк шәһәрендәге дәһшәтле «Кара дельфин» колониясенә озаттылар.

Кемнең җиңел кулыннан киткәндер, бездә бит уракны да сугыш белән бәйләп, «битва за урожай» дип атыйлар. «Дошман явы ауган кебек, ава печән пакусы» дип җырлый бит Илһам абзый да. Ярый әле, сыерны танк, сарыкларны БТР белән чагыштырып җырламый, фәләнчә танкны сугымга озаттык, фәләнчә БТР корбан бәйрәменә китте дип сөйлисе булыр иде хуҗалык җитәкчеләренә.

Әмма бер әйбер күңелне кыра. Инде бездә әллә нинди айти-майти парклар ачылып бетте, XXI гасырда яши башлаганга әллә никадәр вакыт үтте, ә менә авыл хуҗалыгы гына һаман да борынгыча яши. Ел саен яз башында семинарга җыелган авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре киңәшмәләрен урысчалатып «Если Всевышний даст дожди, будет хороший урожай» дип тәмамлыйлар. Кем ничек уйлыйдыр, әмма безнең уңыш тулысынча күктәге яңгырга гына бәйле икән, бу инде авыл хуҗалыгы түгел, һәвәскәр бакчачылык дип аталырга тиеш кебек. Бәй, тулысынча «Всевышний»га бәйле икәнбез, нигә тырышырга, бәлки, авыл хуҗалыгы өлкәсен мөфтигә генә тапшырырга да, вәссәлам. Бик җайлы.

Без инде һәр яктан беренче булырга күнеккән идек. Узган атна азагында Татарстанга килгән Россия авыл хуҗалыгы министры Николай Федоров һавадан җиргә төшерде. Дөрес, республика алдынгылар исемлегендә, әмма кайбер күрсәткечләр буенча безне берничә тапкырга алдырган өлкәләр дә бар икән. Мәсәлән, авылга ярдәм күләме буенча, күрше Чувашия күптән алдырган. Без бүген шәхси хуҗалыкларга 37 миллиард сумлык акча кертелгән дип белсәк, аларның 2010 елда 60 миллиард булган.

Казанлыларны да тагын бер җиңү көтә. «Метроэлектротранс» җитәкчесе Әсфән Галәвов киләсе елга «Икеа» кибете янында метроның икенче линиясе төзелә башлаячак дип куандырды. Казанның меңьеллыгы алдыннан метро төзелә башлагач: «Метро кирәкми, акчаны җиргә күмү ул», – дип бик шаулаган пессимистлар да бүген бик матур гына метрога утырып йөри әле, «Әййем, кирәк түгел, автобус җайлырак», – дип әйткәннәре юк.

# Менә дигән итеп яшиләр

Зөлфия Хәлиуллина

Питрәчтә бу көннәрдә өй туйлары гөрли. Анда 32 гаилә яңа фатирлы булды, Пановка авылында мәдәният йорты ачылды. Бәйрәм чараларында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.



1


2


3

Зур юлдан Питрәч районының Пановка авылын узып киткәндә, йөрәк кысылып куйгандай була. Әллә каян күренеп торган тимерчыбыклы рәшәткәләр биредә тоткыннар яшәгәнлеген гел искәртеп тора. Бу юлы исә Пановкага бәйрәмгә дип атап килдек. 200 тамашачыга исәпләнгән мәдәният йорты ачылачак икән. Куанычлы мәшәкатьләрне күзәтеп торуы бигрәк рәхәт. Биючеләр берсен-берсе алмаштыра, хорга апалар тезелеште, кызлар чәк-чәкләрне әзерләп куйды... Авыл тарихына язылып куелачак матур мизгелләр. Шөкер, мондый күңелле вакыйгалар республикабызда еш булып тора. Авылларны саклап калуны күздә тотып, һәр авылны мәдәният йортлы итү программасы кысаларында, Татарстанда барлыгы 9000 тамашачыга исәпләнгән 47 яңа мәдәният йорты төзелә. Һәр яңа объект авыл өчен бик мөһим, ул аңа яңа бизәк өсти, шундагы халык күңеленә дә өмет сала.

Мәдәният йортын ачу тантанасына килгән Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин дә үзенең чыгышында:

– Безгә халыкны авыл җиренә җәлеп итәргә кирәк. Питрәчлеләр бу уңайдан уңышлы эшлиләр. Йортлар салалар, төзелеш гөрли, яңа эш урыннары булдыралар, – диде.

Мария Завялова – Пановкадагы банкта халыкка хезмәт күрсәтә. Яңа мәдәният йортыннан аңа да эш урыны биргәннәр.

– Кайчандыр үзешчән сәнгатьтә бик яратып катнаша идем, куанычтан, уңайланып китеп сәхнәгә кире кайтырмын кебек, – дип, өстәл астыннан култык таякларын өстерәп чыгарып, җәһәт кенә торып та басты ул. Күз тимәсен, бар авылга җитәрлек оптимизм Мария ханымда.

Казанга якын урнашуы сәбәптерме, соңгы елларда Питрәч районына күченеп кайтучылар саны арткан. Демографик хәл дә уңай якка үзгәрә. Бу исә, әлбәттә, районга җан кертә, яңа биналар сафка баса, эш урыннары булдырыла.

– Питрәч районы Татарстанда тормышка ашырылучы социаль программаларда актив катнаша, төзелеш, реконструкция, модернизация кебек эшләргә безнең районга гына 500 миллион сумнан артык акча каралган, – диде район башлыгы Эдуард Дияров.

Пановка авылыннан соң, Питрәчтә урнашкан яңа бистәгә барып, фатир ачкычлары тапшыру тантанасында да катнаштык. Кайчандыр ялан кыр булган җирдә берсеннән-берсе купшырак күпфатирлы йортлар тезелгән. Бу көнне әлеге йорттан социаль ипотека программасы буенча бюджет өлкәсендә эшләүче 32 гаилә һәм ятим балаларны тораклы итү программасы буенча дүрт балага фатирлар тапшырылды.

Кулына кызыл тасма белән ачкыч тотып, орчык кебек бөтерелүче Әминәне күрмәскә һич мөмкин түгел. Бүгенге бәйрәмнең сәбәбен аңлап бетермәсә дә, әти-әнисе шат булганга ул да куана.

– 2012 елда чиратка баскан идек, Аллага шөкер, ике бүлмәле фатир алдык, – ди Рузилә Хәкимова.

Социаль ипотека буенча Питрәч районында соңгы өч елда тугыз мең квадрат метрга якын мәйданда торак тапшырылган, 87 гаилә чиратта тора. Ноябрь аенда 27 фатирга исәпләнгән тагын бер йорт куллануга тапшырылачак.

– Әниебез вафат булганда, миңа алты яшь иде, – ди Елена. Ул ятимлектә үскән, гаиләдә өлкән бала. – Балалар йортын да, приютын да күрдек. Үзебезне бер гаилә тәрбиягә алган иде, анда да җылылык тапмадык. Рәхмәт туган апабызга, ул үз канаты астына алды, мин медицина көллиятен тәмамладым, энем пешекче һөнәрен үзләштерде. Безнең икебезгә ике фатир бирделәр, һәркайсыбызның үз оясы. Шатлыгыбыз чиксез, бар кешегә дә бик зур рәхмәт!

Авылда яшьләр калсын дисәк, торак йортлар, мәдәни биналар белән беррәттән эш белән тәэмин итүне дә кайгырту бик мөһим. Питрәчлеләр бу юнәлештә дә уңышка ирешеп киләләр. Бутырка авылында урнашкан мәрсин балыгын (осетр) үрчетү заводының февраль аенда беренче этабы тапшырылган булган, якын киләчәктә заводны зурайту күздә тотыла, бер елга 12000 тонна балык җитештерәчәкләр.

**1.** Мәдәният йорты 200 тамашачыга исәпләнгән.
**2.** Хәкимовлар гаиләсе ике елда фатирлы булды.
**3.** Елена һәм Артур да үз фатирларына күченде.

# Штрафлар юлга аркылы төшмәсен

Дамир Бәдриев

**БЕЛЕП ТОР!**

Татарстанда спиртлы эчемлек куллanып руль артына утырган өчен салынган 50шәр мең сум штрафны 192 кеше һаман түләмичә йөри. Ә юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен салынган штрафны түләү вакыты – 60 көн. Моңа штрафны кире кагу, ягъни ризасызлык белдерү өчен тагын 10 көн өстәлә.

«Татмедиа» агентлыгында узган матбугат конференциясендә штрафларны түләмичә йөрүнең шактый күңелсез хәлләргә калдыру мөмкинлеген кисәттеләр. Республикада быелның алты аенда 10953 административ эш кузгатылган, штрафын түләмәүче 3924 кешегә карата суд кулга алу карары чыгарган.

– Әгәр дә кеше, мисал өчен, 500 сум штрафны үз вакытында түләмәсә, әлеге суммага – 1500, ә юридик затларга 10500 сум өстәп түләргә туры киләчәк, – диде ЮХИДИ идарәсенең административ законнарны үтәтү бүлеге җитәкчесе Илһам Кәлимуллин.

Аның фикерен дәвам итеп, Татарстан Республикасы суд приставлары федераль хезмәте идарәсе җитәкчесе урынбасары Алексей Гришин:

– Түләнелмәгән штрафлар 3 мең сумга кадәр җыелса, автомобиль салонындагы милеккә (магнитофон, антирадар, навигатор, һ.б.) һәм транспорт чарасының үзенә административ арест салына, – дип аңлатма бирде.

Чит илгә ялга яки командировкага җыенганда штраф «койрыкларыңны» өзү хәерле. Илһам Кәлимуллин әйтүенчә, республикада 12 мең кешенең штрафлары 10 мең сумнан артып киткән. Хәзер автомобиль юлларында «Юл приставы» аппарат-программа комплексы нәтиҗәле кулланыла. Әлеге аппарат транспорт чарасының дәүләт теркәү билгесе аша түләнмәгән штрафы булган кешене секундлар эчендә ачыклый.

Илһам Кәлимуллин сүзләренә караганда, штрафларны 10 көн эчендә түләгән очракта, 50 процент ташлама ясалуы турындагы закон проекты Россия Дәүләт Думасында өйрәнелә, хәзергә мондый закон юк.

### САН

Быел 1325 «бурычлы автомобиль» туктатылган, 3799 мең сум штраф мәҗбүри түләттерелгән, 17 очракта милеккә арест салынган.

# ТЫЯРГА ИКӘН ТЫЯРГА!

Соңгы вакытта Россия җитәкчелеге берсеннән-берсе кызыклы законнар чыгара: әле тәмәке тартуны тыя, әле сүгенүне. Бу тыюлар безгә шулхәтле ошый, матбугат чаралары уздырган сораштыруларга карасаң, бөтен халык шуны гына көтеп утырган диярсең. Аллага шөкер, халкыбызның теләге тагын кабул булды, дип уйлап куясың.

**Бөтен җитешсезлекләрнең нигезендә...**

Чынлап та, тәмәке тартуны тыю хуплауга гына лаек. Шулкадәр кыйбат бәягә чир сатып алып, дөнья сасытып йөрмәсеннәр. Сәламәтлекләре дә какшамас, акчалары да янга калыр.

Бер данә сигарет атны үтерергә сәләтле, диләр. Бу сүзләрнең дөреслегенә шик юк. Ышанмасагыз, элек гөрләп торган авылларга барып, фермаларга кереп карагыз. Анда атлар калса да, бармак белән генә санарлык. Алары да менә–менә аяк сузам дип тора. Барысы да шул тәмәке аркасында бит инде. Әле чынлап тикшереп карасаң, ул тәмәке атларны гына түгел, сыерларны, сарык вә кәҗәләрне дә үтерә торгандыр. Алары да бетеп бара бит авылда. Ялгыш авыл хуҗалыгы сәясәтен гаепли күрмәгез. Сәясәт булса, гомум хуҗалыкларда гына бетәр иде ул. Ә тәмәке – явыз шәхси хуҗалыкларның да бөтен мал-туарын кырып ташлаган.

Ныклап тикшерсәң, ул тәмәкенең әллә нинди зыяннары бардыр әле. Туган–үскән җирдән дә биздерә торгандыр әле ул. Сезнең авылда тәмәке тарталармы? Тарталар. Ә тәмәке тарткан урында кемнең торасы килсен? Мин үзем бер минут та тора алмыйм. Башкалар да шулайдыр. Шуңа күрә авылларны ташлап читкә китәләрдер. Бөтенләй ташларга хуты булмаганнар, әнә, вахта белән Себергә булса да чыгып кача бит. Ә авылда карт-корылар, хатын-кызлар гына торып кала... Боларның барысына да тәмәке гаепле бит инде.

Ярый, авылы бер хәл әле. Менә шәһәргә килеп төшү белән борыныгызны сасы ис томалаганын тойганыгыз бармы? Юк инде... Завод-фабрикаларның бер гаебе дә юк монда. Элегрәк булса әйтер идегез, ә хәзер... Соң ул заводларның күбесе эшләми бит инде, СССР белән Россия чигендә туктап калдылар. Барысына да нәрсә гаепле дип уйлыйсыз?

Россия – дөньяда экологик яктан иң нык пычранган дәүләтләрнең берсе. Һавасыннан башлап су астына кадәр производство калдыклары, зарарлы химикатлар белән тулган. Бу халыкның сәламәтлегенә зыян сала: һәртөрле гариплекләр, нәселдән нәселгә күчүче авырулар барлыкка китерә. Экологиянең пычрануына да шул тәмәке гаепле бит инде.

Игътибар иткәнегез булса, төрле даирәләрдә яшь буынның беркадәр инфантильлеге, аң-белемгә омтылышы булмаудан зарланалар. Кайберләре хәтта дипломнарны да укып–нитеп тормыйча, сатып кына алалар икән, диләр. Шуңа күрә, бик күп тармакларда үзенең нәрсә эшләгәнен дә белми торган надан белгечләр барлыкка килә. Ә башкача булуы мөмкин дә түгел. Ул тәмәке тарткан ата-аналардан нинди юньле бала тусын!

Күпме җинаятьләр барлыкка килә шул тәмәке аркасында. Кич. Урамнан ялгыз китеп барасың. Ниндидер почмакта бер шәүлә пәйда була:

– Тартырга бир әле...

Ә син бүген туган кеше түгел, тозны күп ашагансың. Һәм хәзер нәрсә буласын алдан ук белеп торасың: син тәмәке кабын чыгаруга ул аны тартып алып кесәсенә тыгып куячак. Яки бер сигаретны алып колак артына кыстыргач, тагын берне сораячак, аннан тагын берне. Һәрхәлдә, аның тартырга соравы бәйләнергә бер сәбәп кенә икәнен син инде беләсең. Һәм әшне кыскарак тотарга теләп, тегенең ияк астына кундырасың... Нәтиҗәдә, йә сине кыйныйлар, йә син кыйныйсың. Ләкин боларның икесе дә начар: кыйнасаң – судка бирәләр, кыйналсаң – хастаханәгә илтәләр... Ә суд юлында йөрсәң дә, медицина тирәсендә дә – кайда да әшең уңсын өчен аз гына ришвәт бирергә туры килә, диләр. Шулайдыр, халык язмышы өчен чын күңелдән тирән борчылып утырган чиновникларыбыз да тәмәке тарта башлагандыр, күрәсең. Ә тәмәке хаклары көннән–көн арта, мескен чиновникның хезмәт хакы гына җитәрлек түгел... Кызганыч, әлбәттә.

Озак санарга булыр иде. Илдәге бөтен җитешсезлекнең нигезендә тәмәке ятуы беркемгә дә сер түгел. Ә газиз хөкүмәтебез шуны аңлап бер законы белән бөтен проблемаларны хәл итте дә куйды.

**Мәдәниятнең иң зур проблемасы**

Зарланырга яраталар инде бездә. Бигрәк тә мәдәният өлкәсендә эшләүчеләр.

– Россия хөкүмәтенең мәдәниятккә бик аз игътибар бирүе, акча бүлгәндә дә калдык принцибы буенча эш итүе – бу тармак хезмәткәрләрен дә, халыкның үзен дә нык борчыган мәсьәләләрнең берсе. Хезмәт хаклары түбән, тузган мәдәният йортлары, клуб бинасы, китапханәләр сипләү таләп итә, заманча җиһазлар, җайланмалар, автотранспорт белән тәэмин ителеш начар, әзерлекле кадрларга кытлык... Югыйсә, нәкъ менә мәдәният һәр халыкның йөзен, дәрәҗәсен билгели, бар өлкәдә уңышларның нигезе булып тора, – дип зар елыйлар алар матбугат битләрендә.

Әлбәттә, сүзләрендә беразхаклык бардыр, утсыз төтен чыкмый диләр бит. Ләкин бу әфәнделәр иң төп проблеманы күрмиләр. Әнә шул проблеманы хәл итми торып, бернинди уңышка да ирешеп булмаячак.

Россия Федерациясе халыкларының мәдәниятен гасырлар буена тоткарлап торган иң зур проблема – сүгенү сүзләре. Лев Толстой иҗатын аласыңмы, Достоевскийнымы – барысы да фәкать сүгенү сүзләреннән генә тора. Ә Максим Горький дигәне шул темага хәтта роман әвәләгән. «Мать» дип атала. Бу, мөгаен, билгеле шагыйрьнең: «Кому на Руси жить хорошо?» – дигән соравына җавап рәвешендә туган әсәрдер.

Репинның «Бурлаки на Волге» дигән нәрсәсен генә алыгыз. Без Россияне сөйрәгән кебек сөйрәп баралар... Аларны сүгенми дип беләсезмени?!

Бу күренеш тирән фаҗига булып мәдәниятебез юлына аркылы яткан һәм аны берничек тә җиңеп булырлык түгел иде. Ярый әле вакытында закон кабул итеп өлгерделәр. Бу закон сүгенү сүзләреннән башка бүтән бер проблемасы да булмаган Россия халыклары мәдәниятен чын мәгънәсендә күтәрү булды.

Менә шуннан соң рәхмәт әйтмичә, нишлисең инде ул җитәкчеләргә?! Без бит аларны нәкъ шуның өчен сайлап куйган идек.

Әлбәттә, мәдәниятнең хәл ителәсе берничә проблемасы калды әле. Спектакльләрдә теге яки бу геройның елавын тыярга кирәк. Елау ул тормышта да матур күренеш түгел. Кешенең күз яшьләрен күрү психологик яктан авыр тәэсир итә, тискәре эмоцияләргә сәбәпче була. Ә сәхнәдән елаганда бу кичереш икеләтә көчәя. Әйтик, яраткан артистканың йөзе ямьсезләнә. Ә сәхнә – ямьсезлек урыны түгел. Төп әшең итеп сәнгать юлын сайлагансың икән, халыкның эстетик таләпләрен исәпкә алып, аның рухи ихтыяҗларына хезмәт итәргә бурычлысың.



МАРАТ КӘБИРОВ

Көлүне тыярга кирәк. Яшерен-батырын түгел, тормышыбыз һәртөрле стресслардан, уңышсызлыклардан да тора. Әйтик, син мең мәшәкатьләрдән арыныргa теләп, театрга килеп утыргансың. Ләкин башында – төрле уйлар, проблемалар. Һәм бер артист сәхнәгә чыгып баса да бер кайгысыз елмаеп тора. Күз алдына китерә аласызмы? Син күңеләңнән ярсып, шартлардай булып утырасың. Ә ул елмая! Бу бит синең күңел халәтеңнән көлү, мыскыл итү. Ул тамашачысын шулай мыскыл итәргә тиешме инде, җә?

Матур киемнәр киеп чыгуны тыярга кирәк. Әйтик, син яңа күлмәккә дигән акчаңа билет алып концертка килеп утырасың. Һәм артист чыга. Фәлән меңлек күлмәк кигән! Коточкыч! Моңа синең еллык хезмәт хакың да җитәрлек түгел. Ник шулай мәсхәрәли ул гади хезмәт кешесен, ник үзеңне мескен тоярга мәҗбүр итә? Дөрес, соңгы арада яшьрәк кызлар кием мәсьәләсендә эконом вариантка күчтә. Ләкин күбрәк акча туплагач яки фигуралары ямьсезләнгәч, алар халыктан көлә башламас, дип кем әйтә ала? Шуңа күрә закон белән туктатырга кирәк бу мәсхәрәне.

Эшләнәсе эшләр, кабул ителәсе законнар җитәрлек, әлбәттә. Дәүләт эшлеклеләребез ярты юлда тукталып калмас, һәртөрле тыюларга сусаган халыкның теләген аяк астына салмас дип көтәбез.

**Ачышлар дәвам итә**

Безнең җитәкчеләребез ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнергә күнекмәгән. Алар һәрдаим эзләнүләр, яңа ачышлар юлында. Бу исә киләчәктә тагы да саллырак, җитдирәк тыюлар көткәнлегенә канатлы өмет бирә, какшамас ышаныч өсти.

Россиядә «придворный шут» сыманрак вазифаны озак еллар буена уңышлы башкарып килгән Жириновский белән бер партиядә торучы Дәүләт Думасы депутаты Роман Худяковның ачышы бөтен дөньяны таң калдыра язды.

Ничек тә булса илнең икътисадый күтәрүне төп максат итеп куйган Худяков озак уйланганнан соң да берни кыра алмагач, фәнни тәҗрибәләр ясауга керешә. Халык арасында иң популяр булган йөз сумлык купюраны сайлый ул үзенең гыйльми эше өчен. Һәм шушы купюраның бәһасен ничек арттырырга дип озак баш вата. Берни дә килеп чыкмагач, аптырап кулына лупа ала: зурайткыч пыяла аша саллы булып күренә ич йөзлек. Ләкин күтмәгәндә... Көтмәгәндә ул йөзлектәге Аполлонның билдән түбән өлеше капланмаган булуын ачыклый. Һәм хафага төшә: «Коточкыч хәл бит бу! Балалар моны күрсә нишләрләр?!» Һәм ул Һиндстанны эзләгәндә ялгыш Американы ачкан Колумб хәлендә ишекле-түрле йөрәнә башлый. Һәм Россия балаларының киләчәк язмышы турында тирән борчылу аны йөз сумлык купюраны гамәлдән чыгару яки дизайнын алыштыру турындагы мәсьәләне күтәрергә мәҗбүр итә.

Илең турында, аның киләчәге хакында хәстәрлекнең героик үрнәге шушы түгелмени?! Кешенең ялангач урыннарын бары тик телевизордан һәм интернеттан гына күреп өйрәнгән балаларыбыз турында кем кайгырта алыр иде шулай?! Үзенең сәламәтлеге хакында да уйламыйча, күзләрен талдырып лупа аша гаурәт эзләп утырырга тагын кем сәләтле Россиядә?!

Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгында рус теле буенча БДИ нәтиҗәләренең түбән булуыннан канәгатьсезлек белдерүләр ишетелә. Моны берәүләр укытучыларның белем дәрәҗәсе түбән дип аңлатса, икенчеләр дәресләр саны аз булу нәтиҗәсе дип карый. Чит ил һәм милли телләр буенча дәресләрне кыскарту исәбенә рус теле һәм әдәбияты дәресләрен арттырырга дигән тәкъдимнәр дә ишетелә.

Күрүебезчә, хөкүмәт безнең хакта онытмый. Яңадан-яңа тыюлар белән сөендереп тора. Димәк, ул әле татар теле укытучыларын да, милләтебезнең башка өлкәләрен дә искә төшерер. Ә без сабыр гына көтик тә, бөтен тыюларны сабыр гына кабул итик. Сабыр төбе – сары алтын диләр бит...

**14 339**

2013 елда Россиянең тикшерү комитеты балаларга карата җинаять кылган өчен шулхәтле эш ачкан

# ЯЗЫЛМЫЙЧА

## Елена Дәүләтова: «Мин үтермәдем, мин батырмадым!»

9 июль көнне Мөслим районы Олы Чакмак авылында ике яше дә тулырга өлгермәгән сабый югалды дигән хәбәр барчабызны да тетрәндерде. Аны эзләүгә авыл, район халкы, волонтерлар кушылды. Ике тәүлек узгач, тагын да тетрәндергеч хәбәр килеп ирешә: мәете табылган, яшь тә сигез айлык Карина Дәүләтова авыл янындагы Ык елгасына батып үлгән.

**Дилбәр Гарифуллина, Илсөя Зәйнуллина**



MAMAGO.RU ФОТО ИЛЛЮСТРАЦИЯ БУЛАРАК БИРЕЛӘ

Олы Чакмак авылы җирлеге башлыгы Илнур Габидуллин «Шәһри Казан»га сөйләгәнчә, кызның әнисе Елена Дәүләтова тәртипсез тормыш алып барган. Аны ана хокукыннан мәхрүм итәргә дә җыенганнар, әмма хатын, эшкә урнашып, тәртипкә утыргач, бу уйдан кире кайтканнар. Шулай булса да, районның социаль яклау бүлеге һәм полиция хезмәткәрләре гаиләне һәрдаим тикшереп-күзәтеп торган. Балаларын Елена үзе генә тәрбияләгән, ирен – беренче баласының атасын дүрт ел әлек урман кискәндә агач басып үтергән. Икенчесен ирсез генә тапкан. Бала белән декрет ялына киткәнче, колхозда төрле эшләрдә эшләп йөргән. Ара-тирә салгаларгә да яраткан. Бу юлы да ул авылга мунча салырга дип килгән шабашниклар белән бәйләнешкән.

Бәхетсезлек буласы көнне Елена улы белән кызын балалар бакчасыннан ала һәм яңа танышлары белән Ык елгасы янына шашлык кыздырып, су кереп ял итәргә дип төшә. Еленаның сүзләренә карaганда, ирләр шашлыкка утын әзерләгәндә дә, итне кыздырырга куйганда да Карина машинада йоклаган. Ә биш яшьлек улы шул тирәдә уйнаган. Шашлык пешкән арада аек булмаган кампания су керергә уйлый. Елена судан чыкканда кызының уянып машина тирәсендә утырып торганын күрә. Ирләргә баланы карый торыгыз дип, кабат суга кереп китә һәм шуннан соң кызын башка күрми. Каринаның кая киткәнен ирләр дә күрми-белми кала. Кызы югалып уникe сәгать үткәч кенә хатын полициягә хәбәр итә.

Каринаны эзләргә Казаннан гына түгел, Чаллы, Түбән Кама, Алабуга шәһәрләреннән, хәтта күрше Мари Эл һәм Башкортстаннан да волонтерлар килә. Иллеләп волонтер белән бергә авыл халкы һәм полиция хезмәткәрләре территорияне квадратларга бүлеп, кызны эзләү эшенә керешә. Яр буен да, көймә белән суга кереп тә эзләп карыйлар алар. Тик нәтиҗәсе генә булмый. Соңрак аларга водолазлар кушыла. Ык елгасы тиз агу сәбәпле, эзләү авыр бара. Карина югалып ике көн узгач кына көймәдәгеләр куаклар арасыннан аның колготкиен күреп ала. Ул якынча баткан урыннан ике ярым чакрым ераклыкка агып киткән була.

Кызын югалткан ана: «Мин үтермәдем, мин батырмадым!» – дип өзгәләнсә дә, бу очракта җаваплылыкның тулысынча ана өстендә булуы хак.

– Тикшерү барышын һәм баланың әнисенә карата нинди маддә буенча җинаять эше ачуны Татарстан буенча Тикшерү комитетының Азнакай районара бүлеге хәл итәчәк, – ди полиция капитаны Айдар Фәхрәзиев.

**PS.** Язманы газетага әзерләгәндә олыларның игътибарсызлыгы аркасында Чаллыда алты яшьлек кыз баланың дүртенче кат тәрәзәсеннән егылып төшүе билгеле булды. Гаилә яңа фатирга күченеп килгәч, баланың әнисе кибеткә чыгып китә. Ә әтисе әйберләр урнаштыру белән мәшгуль була. Агыйна тәгәрмәчле тимераяклар кигән кыз ачык торган тәрәзә төбенә менә дә чебен-черкигә каршы куелган сеткага терәлә һәм аның белән егылып төшә. Бәхеткә, үлән өстенә килеп төшкән бала исән калган.

### АЯНЫЧ

2013 елның 19 февралендә Алабугада 8 яшьлек кыз мәктәпкә барып җитә алмыйча җинаятьче корбаны була язган иде. Кар өстендә дүрт сәгатькә якын яткан кызны мәктәптән ерак булмаган парктагы чокырда аңсыз хәлдә табып алалар. Күп балалы гаиләдә тәрбияләнгән кыз шулай ук кыйналган һәм көчләнгән була. Шөкер, ул исән калды.

### АЯНЫЧ

2013 елның 2 февралендә Чаллыда бию түгәрәгеннән өенә кайтканда күп балалы гаиләдә тәрбияләнүче 8 яшьлек Василиса Галицына югалган иде. Аның гәүдәсе алты көн узгач кына табылды. Кыз чыгышы белән Үзбәкстаннан булган 30 яшьлек Фәррух Ташбаев кулыннан һәлак булган. Баланың калак сөяге турысында пычактан яра, тәнендә күпсанлы тырналудан җәрәхәтләр һәм көчләү эзләре булу ачыкланды

### КОММЕНТАРИЙ

**АЛСУ МӨХӘММӘТОВА,**
Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат белән хезмәтәшлек буенча әйдәп баручы киңәшчесе:

– Балалар өчен җаваплылыкны дәүләт җилкәсенә генә салырга ярамый, төп эш әти-әниләр өстендә булырга тиеш. Балалар бакчаларда, мәктәпләрдә булган чакта алар бик зур игътибар һәм сак астында тотылалар. Аларның сәламәт, тук булулары өчен җавап бирәбез. Бакчаларда да балаларга ут белән сак кылыну, таныш булмаган кешеләр белән сөйләшмәү турында төшендереп кенә торабыз. Әммa әти-әниләрнең тырышлыгы бик кирәк. Күптән түгел генә бер тапшыру карадым. Балалар белән эксперимент уздырдылар анда. Балалар комлыкта уйныйлар, әти-әниләре читтән карап тора. Балалар янына психолог килде дә, бернича минут сөйләшкәннән соң, балалар аның артыннан ияреп киттеләр дә бардылар. Ун баланың берсе генә: «Мин сезнең белән бармыйм, хәзер әнием килә», – дип басып калды.

**Татарстанда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачина фикеренчә, балалар белән бәхетсезлек очракларының күбесендә ата-аналар гаепле. Нәкъ менә аларның балаларын тиешле дәрәҗәдә карамавы, сабыйларын тәрбияләү буенча бурычларын тиешенчә үтәмәве, нәниләрнең караучысыз булуы фаҗигагә китерә дә инде, ди ул.**

**МАРАТ ФӘТТИЕВ,**
Казандагы 4нче кызлар гимназия-интернаты директоры:

– Мәктәп балалар мәктәптә булган чакта аларны саклау нисбәтеннән төрле чаралар күрә. Сак хезмәте дә бар, балалар белән дәресләрдә дә, сыйныф сәгатьләрендә дә аңлату эшләре күп алып барыла. Бездә үсмер кызлар укыгач, алар белән бигрәк тә сөйләшүләр күп уздырыла. Төрле саклану чаралары, чит кешеләр белән үзләрен ничек тоту кагыйдәләре аңлатыла. Ә инде башлангыч сыйныф укучыларына килгәндә, алар өчен әти-әниләр күбрәк җаваплы. Баланы өйдән үзен генә чыгарып җибәрү дөрес эш түгел. Ул бит үзен яклый да, берәр нәрсә булса, ярдәм дә күрсәтә алмый.

**ГӨЛНАРА АБДУЛХАЕВА,**
Казанның Авиатөзелеш районындагы 51 нче балалар бакчасы мөдире:

– Балалар бакчада ныклы сак астында. Безнең бакчада электрон йозак системасы, ачкычы әти-әниләргә генә бирелгән, ишектән чит кеше керә алмый. Зур капкалар көне буе ябык, видеокүзәтү системасы урнаштырылган, 6 төркемле бакчабызда 8 камера бар. Язмалары бер айга кадәр саклана. Бакчаны 24 сәгать дәвамында ОМОН саклый, тревога төймәләре ике катта да бар. Тикшереп караганыбыз бар, сигнал барган очракта, ике минут эченә әйдә килеп җитәләр. Балалар урамга чыкканчы, тәрбиячеләр иң элек алар уйнаячак мәйданнарны бер кат тикшереп чыгалар, тәрбиячеләр белән инструктажлар даими үткәрелеп тора. Балаларны чит кешеләргә бирмибез, кич алып мөмкинлекләре булмаса, иртән ата-аналар баланы кем алачагын тәрбиячегә әйтеп, ул кешенең паспорт күчермәсен калдырып китәләр.

**15 470** узган ел Россиядә балигъ булмаган шулхәтле сабый зыян күрүче дип табылган, аларның 10 проценты туганнары кулыннан зыян күргән

# КАЛГАН ЯЗМЫШЛАР

## Биш бала анасы Йолдыз Шәрәпова: «Ярату булмаганга сабыйлар мәңгелеккә китә»

Ел саен июньнең берендә, чәчәкле җәй башланганда бөтен дөнья Халыкара балаларны яклау көнен билгеләп үтә. Бу тикмәгә генә түгел, балалар үзләре дә тормышыбыз чәчәкләре бит алар. Дөрес, кайберәүләр 1 июньнең нинди көн икәнен, аның әһәмиятен аңлап та бетермиләр. «Балаларны кемнән якларга кирәк соң, алар болай да якланган бит инде»,– диләр. Юк шул, якланмаган.



Әйе, сабыйларыбызга әкияттәге җиде башлы дию пәрие янамый, ләкин нәни саф җаннарны аларның тирә-юнендәге юньсез өлкәннәрдән (гадел булмаган укытучылар, явыз тәрбиячеләр һәм, кызганыч, соңгы вакытта...әти-әниләреннән дә!), җыеп кына әйткәндә, тормышның бөтен пычраклыкларыннан якларга кирәк. Бу бүгенге гаделсезлек белән шыплап тулган дөньяда җиңел түгел. Ләкин шулай да без, өлкәннәр, моны эшләргә тиешбез. Чөнки бер генә сабый да дөньяга үзе теләп, гариза язып килми. Ләкин без еш кына бу хакта белмибез, әллә белергә дә теләмибез, әллә белеп тә онытабыз, әллә белмәмешкә салышып, күз йомабыз.

Кадерен белмәсәң, каберен белерсең диләр бит. Соңгы араларда мәңгелек йортыбыз - зиратларда елдан-ел нәни каберләр саны арта бара. Ул нәни туфрак өемнәре астында кемнәрнеңдер йөрәк парәләре, җан яралары мәңгелек йокыда. «Бала хәсрәте бирмәсен!» - бу безнең халыкның иң изге теләкләренең берсе. Чөнки бала хәсрәте иң авыры, җанны иң әрнеткәне. Башта аны тугыз ай буе төрле җәфаларга түзеп, йөрәгең астында йөртәсең, аннары мең газаплар, әҗәл белән күзгә-күз очрашып, дөньяга китерәсең.

– Безнең тормышыбызда мәхәббәт кимеде, – ди бер педагог психолог танышым. – Безнең бөтен фаҗигаләребез шуннан башлана. Әтиәниләр – балаларын, балалар ата-аналарын яратмый, хөрмәт итми. Моннан иң күп җәфа күрүчеләр, билгеле инде, балалар.

Без шул әбиләребез әйткән «ата – улны, ана кызны белми торган» заманга килеп җиттек бугай. Югыйсә, бәгырь җимешләребезгә болай ук битараф, игътибарсыз булмас идек. Соңгы хәбәрләрне куркып, тагын ни булды икән инде, дип тыңлыйбыз хәзер. Тегендә самолет төшкән, монда янгын чыккан, олы юлда машина һәлакәте. Күпме җаннар кыелган. Иң аянычлысы, алар арасында әле яши генә башлаган, күпме гөнаһсыз нарасыйларның булуы бәгырьне телә. Өч ел элек «Булгария» фаҗигасендә 28 сабыебызны югалттык. Ә күпме тумый калган сабыйлар әниләренең карынында мәңгелеккә күчтеләр. Ләкин без, бүген, нишләптер, гыйбрәт тә, сабак та ала белми торган бер мәгънәсез кавемгә әйләнеп барабыз бугай. Йөрәкләребез урынында да кайгырта да, ярата да, борчыла да белми торган йодрык кадәрле ит кисәге генә бугай хәзер. Күзләребез дә сөеп карарга сәләтле түгел, ә аракы сөреме яисә акча ялтыравы белән генә капланган бугай. Шуңа күрә дә сабыйларыбыз бездән китеп торадыр да. Безнең битарафлыгыбызга, яратуыбыз җитмәүгә түзә алмыйча, мәңгелеккә...

Әле кыш көне генә өе белән музыка мәктәбе арасында югалган ун яшьлек Чаллы кызын эзләдек. Инде менә Мөслим районындагы фаҗига күпләрне тетрәндергәндер. Ике яшьлек сабыен яр буенда утыртып, су керергә төшеп киткән хәсрәт-ана сабыеның елау тавышы төшләренә кереп, акылдан язмасмы икән? Юктыр, чөнки акылдан язар өчен дә башта ул акылның булуы кирәк бит әле. Ә акыллы әни нәни баланы су буенда берүзен калдырмый. Төркиягә ял итәргә барып, алты яшьлек улының гомерен массажга алмаштырган ханымга ни дисең тагын?!

Сүз уңаеннан шуны да әйтәсем килә, Казанда терелүгә өметләре өзелгән, онкология чиреннән җәфаланучы балалар өчен хоспис та (аны икенче төрле фәрештәләр йорты дип тә атыйлар) 1 июнь көнне ачылды. Ләкин бу бер дә мактана, шатлана торган вакыйга түгел, күз яшьләре аша елмаерга тырышу гына.

Уеннан уймак чыккан Украинада, өлкәннәр тәхет, дан һәм байлык бүлешкәнгә иң яклаучысыз төркем балалар гомерләре белән түли. Славянск шәһәрен бомбага тотканда, утыз ярчык тиеп үлгән ун айлык сабый турында ишеткәч, җаны булган һәркемнең йөрәге кысылып куйгандыр. Ул сабыйда аның хәтле ядрәне сыйдырырлык баш та юк бит әле, ике кушуч кадәр генә. Боларны ишеткәч, күргәч, бөтен дөньяны яңгыратып: «Туктагыз, кешеләр, сез нишлисез? Киләчәксез каласыз бит!» – дип кычкырасы килә. Ләкин туплар тавышланганда андый җан авазын кем ишетер икән?! Аны ишетер өчен тупларның туктавы кирәк шул.

Мондый кайгылы хәлләр турында ишеткәч, үзебезнең әбиләребезне искә алам мин. Алар ирләрен сугышка озатканда итәк тулы берсеннән-берсе кечкенә балалар белән калганнар. Ләкин үзләре бик күп авырлыклар күрсәләр, ач-ялангач булсалар да, һәрберсенең гомере өчен кыя таштай нык торганнар. «Бармакның кайсын гына тешләсәң дә, бер төсле авырта», – дигәннәр алар һәм бик хаклы булганнар. Ирләре яу кырында батырлык күрсәтсә, алар тылда Ана батырлыгы күрсәткән. Шуңа күрә җиңгәнбез дә инде без. Күп кенә җирләрдә солдатлар белән янәшәдә Аналар батырлыгына да һәйкәл куелган.

Ничә тапкыр игътибар иткәнем бар, бала югалту кебек ачы хәсрәт кичергәннәр бу фаҗигадә бөтен тирә-юньне гаеплиләр, тик үзләрен генә түгел. Кемдер карарга тиеш булган, кемгәдер ышанып калдырган... Юк инде, әти-әниләр (бигрәк тә әниләр!), төп гаеп сезнең үзегездә. Чөнки сез бит аның дөньяга кирәклеген тоеп, аңа яңа тормыш биргәнсез. Ә тормышына куркыныч янаганда нигә янында булмадыгыз? Нигә аны кеп-кечкенә явыз үлемгә бирдегез?

Исегезгә төшерегез әле, нәни балалар куркыныч килгәндә (юл аша чыкканда, эт очраганда, исерекләр күргәндә) әниләренең яки башка үзләре өчен кадерле кешеләрнең кулларына ябыша. Һәрхәлдә, минекеләр генә искәрмә түгелдер. Алар бу чакта кулларын гына түгел, дөпдөп типкән йөрәкләрен дә (гомерләрен дә дип укыгыз) без өлкәннәргә тапшыралар.

Балаларны 1 июньдә генә түгел, һәркөнне яклыйк!

## Ул әни булалмады

Илфак Шиһапов



Әллә нинди чәчләр үрә торырлык хәбәрләргә дә ияләшеп беттек бугай инде. Тегендә юл һәлакәте, монда гаилә трагедиясе – саный китсәң, күп инде алар. Матбугат чараларының да күбесе шундыйрак темаларга аерым игътибар бирә, чөнки газета укучы Казанда утыртылган матур гөлләр турында түгел, кемнеңдер кайгысы турында теләбрәк укый башлады. Өйрәнелде инде. Күңел бик тартмаса да укыйбыз. Ләкин һич кенә дә өйрәнеп, күнегеп булмый торган бер нәрсә бар – ул да булса, балалар, сабыйлар белән булган фаҗига.

Ике яше дә тулмаган Карина Дәүләтова турындагы хәбәрне ишетеп тетрәнмәгән кеше калмагандыр. Бер телеканал төшергән видеосюжетта Каринаның әнисе бу көнне дә салган булганын яшерми дә. Аңлашылганча, ана кеше кемнәрдер белән Ык буенда «ял иткән», баланың барлыгын белүче дә булмаган.

Иң аянычы шунда, мондый хәлләр дә гадәтигә әйләнеп килә бугай. Көн саен булмаса да, атна саен моңа охшаш хәлләр турында ишетеп, укып, күреп торабыз. Бала ана кеше өчен җирдәге иң кадерле җан иясе булырга тиеш тә бит, нишлисең.

Әле күптән түгел генә, бер авылда кич белән урам буйлап көч-хәл белән атлаучы «ана»ны күреп исем китеп утырган идем. Тиле кеше сыман үзалдына елмаеп, кайдандыр «ял итеп» кайтучы яшь хатынга өч баласы ияргән. Олысына җиде яшьләр тирәсе, кечесенә - яшь ярым чамасыдыр. Абына-сөртенә ана атлый, аның артыннан тезелешеп балалар бара. Татар авылы сөрлегеп китеп җиргә тезләнгән әниләрен торгызырга маташкан балалар күренеше белән берничек тә ярашмый кебек. Ләкин авыл моңа да күнеккән инде. Чөнки андыйлар бүген генә барлыкка килмәгән, андый хатыннар авылда берәү генә дә түгел.

Бер якын танышым эчә торган хатын-кызны күрсә: «И-и-и, хайваннар, ирләр ризыгына үреләләр бит», – дип әйтә иде. Чыннан да эчкән ир гадәти хәл итеп кабул ителсә, эчкән хатын-кыз исә – җирәндергеч күренеш. Ә эчеп йөреп баласын да оныткан ана кеше?!

Суга батып үлгән ике яшьлек сабый. Исән булса, алда нинди тормыш көткән икән аны? Гадәттә, авыррак тормышта, ата-ана назы, игътибар җитми үскән балалар әрсезрәк була. Тормышка чытырдап ябыша, чөнки тамаклары туймаган көннәре күңелләреннән чыкмый. Карина да бәлки чибәр, акыллы, уңышларга ирешүче кыз булып җитешеп, гаилә корып, балалар үстергән булыр иде...

Инде тарихта калган, берүзе эреле-ваклы биш баласын, авыру каенанасын ач-ялангач итмичә карап, шуларга ризык булсын дип басудан курка-курка арыш уган, язын билдән салкын суда йөреп черек бәрәңге җыйган әбиләрне уйлап утырам. Алар да ана, болар да. Аналарның да төрлесе була шул...

# ТУЛАЙ ТОРАК ШУЛПАСЫ

Балаларын башкалага укырга озатучы әти-әниләргә дә ярдәм-белешмә булсын дип, без бүген Казан тулай торакларына юл алдык.



Алисә Сабирова

### Алтын читлекме, ирекме?

2010 елдан КФУ студентлары Россиянең иң яхшы студентлар кампусы дип саналган Универсиада авылында да яши башлады.

Универсиада авылын, катгый кагыйдәләре өчен, студентлар телендә «Алтын читлек» дип йөртәләр. Үземә дә әлеге кампуста өч ел яшәргә насыйп булды. Шуңа андагы тормыш белән яхшы таныш мин. Әле төзелеп кенә беткән яңа биналар, кибет киштәләреннән кичә генә чыккан җиһазлар, евроремонт – болар барысы да җәннәткә тиң шартлар. Кешеләр ничә ел Казанда торып та мондагыдай шәп «фатир»ларда яши алмый, ә безгә укырга кергән өчен генә дә җәннәт оясы эләкте.

Эйфория беренче радиохәбәрдән соң тиз таралды (монда бүлмә саен радиорубка куелган). Вахтер бүлмәдә нәрсә эшләргә ярый, нәрсә эшләргә ярамаганлыгын санап чыккач, үзебезне чыннан да «алтын читлек»тә дип хис итә башладык. Шул байлыкны Универсиада уеннарына кадәр «өф» итеп саклап ятарга туры килде. Сакламый кая барасың, җиһазда бер генә тырналган яки сыдырылган эз күренсә дә, студент кесәсеннән чыга бит ул.

Студент тормышы ул бертуктаусыз китап укып яту гына түгел, ял да итәргә кирәк. Универсиада авылында ял итү өчен барлык шартлар да тудырылган. Укудан соң велосипедта, роликларда йөри аласың, кыш көне шугалак эшли. Яшьләр спорт белән шөгыльләнә, кичләрен күбесе йөгерергә чыга. Студентлар үз көче белән ясаган спорт мәйданчыгы да бар. Яз, җәй авыл төнгә кадәр гөрли, кемдер гитарага кушылып җырлый, кемдер урамда бушка wi–fi ярдәмендә кинофильмнар карый, аралаша.

Универсиада авылы уңайлы шартлар яратучылар өчен булса, студентлар шәһәрчеге – ирек сөючеләр куышы. Гадел Кутуй, Кызыл Позиция, Пушкин урамнарында урнашкан тулай торакларда яшәгән студентлар әле дә ул елларны сагынып искә ала. Ул тулай торакларда тотарга да курка торган кыйммәтле җиһазлар юк, барысы да, ким дигәндә, 20 еллык, Сәвит заманыннан калган әйберләр. Борыныңны чөеп, мин кем дип йөрмәсәң, монда да яшәмәслек түгел.

Студентлар шәһәрчегендә яшәү бәясе аена 80 сум булса, Универсиада авылында – 180 сум. Вуз администрациясе аңлатуынча, Универсиада авылында һәр кешегә 8-9 квадрат метр мәйдан туры килә, ә бу Россия вузлары тулай тораклары өчен билгеләнгән нормативтан, ягъни 6 квадрат метрдан күбрәк. Шуңа күрә бәяләрдә дә аерма бар.

КФУның барлык тулай торакларында да энергия күп сарыф итә торган җиһазлардан файдаланган өчен өстәмә түләүләр дә каралган. Студентлар электр чәйнеге һәм суыткыч өчен 72 сум, компьютер – 115 сум, ноутбук – 37 сум, микродулкынлы мич – 30 сум, үтүк – 11 сум, телевизор өчен 9 сум түләргә тиеш була.

Студентлар шәһәрчегенең бер үзгә ягын да онытмаска кирәк – җәен бүлмәләр мунча кебек эссе булса, кыш көне салкында яшәргә туры килә. Шуңа күрә үзегез белән җылыткыч та кыстырып килергә онытмагыз. Аны кулланган өчен студент кесәсеннән тагын 484 сум 80 тиен чыгачак.

### Көнгә – ун сум

Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты (КАИ) карамагында җиде тулай торак бар, анда бюджет хисабына укучы башка шәһәрләрдән килгән студентлар һәм ташламалы категориягә керүче яшьләр (ятимнәр, инвалидлар һ.б.) яши. Түләүле уку бүлегендә белем алучы студентлар өчен дә тулай торакта урыннар каралган. Монда яшәү бәясе – аена 296 сум 46 тиен.

Көненә 10 сум – бу әллә ни кыйммәт бәя түгел. Моңа урын–җирне юу, саклау камералары һәм каравылчы хезмәте дә керә, – дип аңлаталар тулай торак администрациясендә.

Студентлар электр энергиясе өчен дә аерым түли. Һәр электр приборын кулланган өчен аерым бәя каралган.

Вуз тулай торакларын идеаль хәлдә дип таныштырса да, студентларның яшәү шартларына үз карашы.





**1** Универсиада авылындагы шартлар.
**2** Студентлар шәһәрчегендәге бүлмә.

– Бүлмәдә дүрт кеше торабыз, бик дус–тату яшибез. Әлбәттә, җитешсезлекләр дә бар. Санузелны дүрт ел эчендә бер тапкыр да ремонтламадылар. Кунаклар чакырырга да оят! Бер блокка уртак аш бүлмәсе. Кайбер студентлар үз артыннан җыештырмый, шуңа күрә ул еш кына чүп оясына әверелә. Барысы да үзебездән тора, студент үзен тиешенчә тотса, яшәгән җир дә чиста-пөхтә булыр иде, – дип сөйләде КАИның беренче тулай торагында яшәгән Айсылу Мостафина.

### «Бездә тиздән өй туе!»

Казан энергетика университетында электр энергиясе өчен өстәмә чыгымнар тулай торакта яшәү хакына кергән. Студентлар һәм аспирантлар өчен тулай торак бәясе аена 300-400 сумга төшә. Уку йортының ике торагы да тулы. Тулай торакның берсе 1983 елда төзелгән. Икенчесе яңарак, анда студентлар 2010 елда гына яши башлаган. Тулай торaклар уку йортыннан 5-10 минутлык арада урнашкан. Беренче тулай торакта китапханә бар, икенче тулай торакта буфет һәм спорт залы эшли.

Кечерәк бүлмәләрдә 2-3 кеше, ә зур бүлмәдә 4-5 кеше яши.

Беренче курслар өчен тулай торакта 652 урын каралган. Бүген университет тагын бер тулай торак төзи. Якын киләчәктә өй туе ясарбыз, дип белдерделәр университет администрациясендә.

Энергоуниверситетта укыганда гына түгел, тулай торакта яшәгәндә дә балл-рейтинг системасы хөкем сөрә. Университет тормышында актив катнашкан студентлар сессиясен дә автоматка яба, тулай торакта да иркенләп яши ала. Ә койрыклары булган студентларга тулай торак бөтенләй тәтеми.

### «Күбрәк авыл балалары яши»

Аграр университетта күбрәк авыл балалары белем ала, шуңа да вуз тулай торакта яшәү чыгымнарын арттырмаска тырыша. Быел тулай торакта яшәү бәясе – 310 сум. Аңа тулай торакта яшәгән өчен – 55 сум һәм өстәмә коммуналь хезмәтләр өчен 255 сум керә.

Университетның алты тулай торагы бар. Шуларның дүртесе Ферма–2дәге уку корпусы янында урнашкан. Ике тулай торак шәһәр үзәгендә. Һәр факультетка, бюджетка ничә кеше кергәненә карап, тулай торакта яшәү урыны бүленә. Барлык урыннарның 15 проценты беренче курсларга бүлеп бирелә. Өлкәнрәк курсларны гаилә хәленә, укуда өлгергәнлегенә, студентлар активында катнашуына карап урнаштыралар. Бер бүлмәдә 2–3 кеше яши. Кунаклар бары кичке алтыга кадәр генә керә ала.

### Югары курслар фатир арендалый

Казан милли тикшеренү технология университетының биш тулай торагы бар. Кагыйдә буларак, аларга башта беренче курс студентларын урнаштыралар. Тулай тoрактан бүлмә кирәк булган очракта, студент кабул итү комиссиясенә документларын тапшырганда ук гариза яза. Калган урыннар югары курслар арасында бүленә. Ләкин икенче курстан да олырак булган студентлар өчен монда урын юк, күбесе фатир арендалый. Тулай торакта яшәү өчен уку елы башында ук түләп куясың. Ул елына 3500 сум тәшкил итә. Кунаклар иртәнге сәгать 9.00 дан кичке 10.00га кадәр керә ала. Монда да энергетика университетындагы кебек балл системасы хөкем сөрә.

– Тиешле баллар җыйсаң, тулай торакта аттестация үтәсең, аның өчен ел әйләнәсендә эшләргә кирәк. Кызлар өчен минималь балл – 80, егетләр өчен – 90. Мин шаяннар һәм тапкырлар клубында, спорт ярышларында катнаштым, бер санитар көнне дә калдырмадым, кухняны юдым. Шулай итеп, барлык балларым 100гә тулды инде, – диде бишенче тулай торакта яшәүче Эдуард Степанов.

Тулай торакта тәртип бозучыларны шунда ук куып чыгаралар яки штраф баллары бирәләр. Урын булмау сәбәпле, өч кешелек бүлмәләрдә дүрт кеше яшәгән очраклар да бар икән.

### Тәртип бозучылар бүлмәләре белән тиз саубуллаша

Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш университетында уку йорты бинасыннан ерак булмаган өч тулай торак бар. Читтән килгән укучыларга монда 840 урын әзерләнә. Студентлар аена 150-170 сум түли. Суыткычы һәм микродулкынлы миче булганнарга яшәү бәясе бермә-бер арта. Университет үзе архитектура, төзелеш өлкәсе белән бәйле булгангамы, тулай торaклары да бик яхшы хәлдә. Берничә ел элек биналарга евроремонт ясалган. Блокта ике санузел, бер кухня һәм душ бар. Һәр блокта егермешәр кеше яши. Шартлар яхшырак булган саен, торакта кагыйдәләр дә кискенрәк була.

– Ничек кумасыннар, кудылар! Биш ел буе тулай торакта яшәгән дәвердә әллә ничә кешенең бүлмәсе белән саубуллашуының шаһиты булдым. Вахтердан качып бүлмәгә балконнан керсәң, исерек килеш дуласаң, икенче көнне үк комендант куып та чыгара. Тулай торакта торганыма бер дә үкенмим. Бик күп дуслар таптым, монда яшәү бик күңелле иде. Минемчә, һәр студент тулай торакта торырга тиеш, – ди институтның чыгарылыш курсы студенты Айдар Вәлиев.

### Интерн һәм ординаторларга аерым бәя

Казан медицина университетының тулай торакларында яшәү 240 сумга төшә. Университетның дүрт тулай торагы бар. Интерн һәм ординаторлар аена – 507, чит ил студентлары 750 сум түли. Яшәү урыннары иң беренче ятимнәр, инвалид студентлар, күп балалы гаиләләрдән булган студентлар өчен бирелә. Икесе дә КДМУда укып, гаилә корган, бала тапкан студентларга, яшәү шартлары яхшырганчы, тулай торакта яшәү мөмкинлеге бар. Ятимнәр тулай торак өчен бөтенләй түләми. Яшәү бәясе, стипендия бәясенең 5 процентыннан да артмый. Уку йортының беренче тулай торагы 160 булачак медикны сыйдыра. Кунаклар кичке 16.00 сәгатьтән 21.00 сәгатькә кадәр вакыт аралыгында гына керә ала.

БЕЗНЕҢ БЕЛЕШМӘ

Фәйзрахманов Илнур Файзияздан улы

«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директорының радио буенча урынбасары

Туган җире – Балык бистәсе районының Юлсубино авылы

Туган көне – 1980 елның 16 августы

Белеме – Казан дәүләт университетының татар журналистикасы бүлеге

Өйләнгән. Тормыш иптәше Гөлназ Фәйзрахманова белән бер малай һәм кыз тәрбиялиләр.



**Илнур ФӘЙЗРАХМАНОВ:**

# «Мин – Путин өчен җавап биргән кеше»

Кайчандыр, дөресрәге моннан ун ел элек, болай гына, сөйләшеп утырганда, бер шактый ук билгеле абзый: „И-и-и, безнең буын картаер, бүгенге яшьләр килер җитәкчелеккә, вәт шунда белерсез әле безнең кадерне„, – дигән иде... Сүз татар матбугаты, башка шул өлкәгә караган нәрсәләр турында барды ул вакытта. Килде кебек ул заман. Безгә кагылышлы күп кенә өлкәдә җитәкчеләр – яшьләр хәзер. Илнур Фәйзрахманов – яңа буын җитәкчелекнең тагын бер вәкиле.

Илфак Шиһапов

**– Илнур, иң беренче, әлбәттә, сәвит журналистикасы традицияләреннән чыкмыйча, үзең турында сорыйм. Туган ягың, гаилә һәм башкалар... Ничек килеп кердең син радио өлкәсенә?**

– Мин Балык бистәсе районының Юлсубино авылыннан. 17 яшьтә авылдан чыгып китеп, Казанда төпләндем. Хатыным белән ике бала үстерәбез. Радиога килеп чыгу очраклылык дияр идем. Тик ул вакыйгадан соң да инде менә 14 ел узып киткән. Радиога ул вакытта инде танылып өлгергән алып баручы Алсу Исмәгыйлева киңәше белән килдем. Беренче тапкыр студиягә кереп текст укып караганда «Шәһри Казан», «Мәгърифәт» газеталары мәктәбен узып, тәҗрибәле каләм ияләренең киңәшләрен сеңдереп өлгергән идем инде.

**– Радиогыз «Болгар радиосы» дип атала. Нигә шулай? Нигә, мәсәлән, «Алтын Урда» радиосы түгел? Белүемчә, бу хакта тыңлаучылар да шактый бәхәсләшә.**

– Ребрендингка тотынгач, чыннан да, шактый сүз ишеттек. Мине Болгариягә сәфәргә теләүчеләр дә, «мәетләр радиосы» дип атаучылар да булды. 2011 елның икенче яртысы иде ул. Тулы куәтенә Болгар шәһәрчеге торгызыла, тарихи сәхифәләр барлана башлады. Шушы вакыйгалар казанында кайнаганда тарихи җирлеккә бәйле атаманы куллануның табигый икәнен аңларга теләмәделәр. Бүген тынычландык шикелле. Аеруча радионың исемен алыштыру финанс планында үз нәтиҗәсен биргәч, үзем дә төрле шәхесләрнең сызгырып оча торган укларына игътибар итми башладым. Шуны гына тәгаенлисем килә: без беркайчан да болгарлашу сәясәте алып бармадык.

**– Бүгенге көндә сезнең аудитория күпме? «Болгар радиосы»н кайларда тыңлыйлар? Татарстаннан читтә тыңлап буламы?**

– Аудиториянең санын тәгаен генә әйтеп бирүче табылмас. 2 миллион тирәсе дисәм, чынбарлыкка якынрак булыр. Безнең максатчан аудитория – 25 яшьтән 45 яшькә кадәрге тыңлаучылар. Потенциаль аудитория дип 15-60 яшьлекләрне санайбыз. Таралу мәйданы – Татарстан, Башкортстан, Самара, Ульян өлкәләре, Мари Эл республикасы, Киров өлкәсенең бер өлеше. Пермь краеның Барда районында 105 ФМ ешлыгында сөйли башладык. «Болгар радиосы» Казан, Татарстаннан тыш, иярчен, интернет аша да җир шары буйлап тарала.

**– Бер тәүлек әйләнәсендә радио эфирында ничә җыр яңгырый? Ничек сайлана алар?**

– Бер сәгать дәвамында уртача унлап җыр яңгырый. Тәүлек әйләнәсе эшлибез. Димәк, 240 җыр. Әмма шунысы бар, популяр һәм түләүле шартларда урнаштырылган җырлар көн дәвамында өч-дүрт мәртәбә кабатлана. Бер тәүлек эшләп тору өчен безгә 200 җыр җитә дип әйтергә була.

**– Сез турыдан-туры эфирда эшлисез, тапшыруларыгыз шактый, алып баручылар да төрле. Кешенең төрле чагы була. «Ялгыш берәр ярамаган сүз ычкындырсалар, нишләрмен?» – дип уйлап, чәчләрең үрә торгаламыймы? Гомумән, андый хәлләр булганы бармы?**

– Әйткәнемчә, мин радиода, бер урында 14 ел эшлим. Шушы вакыт эчендә алып баручылар сафы, нигездә, даими сакланды дияргә була. Иң соңгы булып килгән алып баручыбыз да бишенче елын эшли инде. Мин һәр алып баручының эфирда ни сөйләячәген алдан ук чамалый алам, шуңа курку юк. Ялгыш сүзләр ычкындыру була, аның өчен эләккәләгәне дә бар. Әмма һәр алып баручының күп еллар дәвамында җыйган репутациясе, эшләп тапкан исеме бар. Һәм, әлбәттә, алар инде үз исемнәренә каршы эшләрлек сүз әйтмәячәк. Мин коллегаларыма ышанам. Аларны һәр җирдә якларга әзермен.

**– Тормыш иптәшең Гөлназ да радиода. Икең бер җирдә эшләү кыен түгелме?**

– Төрле чак була, тик бер бик яхшы ягы бар – эштәге борчуларны уртага салып сөйләшергә мөмкин. Минем кәефсез кайтканны да, очының йөргәнне дә Гөлназ аңлый. Монысы өйдә. Ә эштә минем өчен хатын юк. Ул гап-гади алып баручы, бернинди өстенлеге юк. Киресенчә, киртәләр аңа күбрәк тә куела әле.

**– Радиога даими шалтыратып торучы берничә кеше бар...**

– Берничә генә түгел, күп алар. Студиягә кереп, стенадагы номерларны карагыз – 150ләп телефон номеры бар анда. Болар инде ВИП-исемлек *(көлә)*. Еш чыгучылар. Эфирда эшләүче алып баручы телефон шылтырап, номеры ачыклангач, шул стенадагы исемлекне карап ала. Таныш номер икән, аны параллель линиягә чыгарып, икенчесен кабул итә.

**– Радионы тәүлегенә ничә сәгать тыңлыйсың?**

– Мин үзебезне генә тыңламыйм. Җыеп әйткәндә, 4-5 сәгать чыга торгандыр. Башкаларны тыңлыйсың, чагыштырасың. Ә гап-гади тыңлаучы буларак, мин Спорт радиосын үз итәм. Күз алдыңа китер: машинада барасың, нинди дә булса матч вакыты... Ә эфирда турыдан-туры трансляция, рәхәт...

**– Радионың киләчәген ничегрәк күз алдына китерәсең? Башка мәгълүмат чаралары белән конкурентлыкны сизәсеңме? Ә башка татарча радиолар сезгә ни дәрәҗәдә конкуренция тудыра?**

– Бүген тыңлаучыны бер дулкында тоту авыр. Сайлау мөмкинлеге дә зур. Төрле форматтагы радиолар булу да тыңлаучы өчен отышлы. Конкуренция нәрсәдән барлыкка килә? Радиоларның күбрәк акча эшләргә омтылышыннан. Ә акчаны төрле оешмалар китерә. Ул оешмаларның җитәкчеләре шулай ук үз зәвыкларына туры килә торган радиоларга өстенлек бирәләр. Күп очракта рейтингка да карaучы юк. Ә рейтинг буенча безгә эшлисе дә эшлисе әле. Хәер, рейтинг шулай ук шартлы әйбер. Монысы икенче бер глобаль тема...

**– Минем карашка, эшләвен заманча эшлисез. Тапшырулар да җитәрлек, җырлар төрлелеге дә бар. Алга таба «шуны эшләргә» дигән нинди план-идеяләрең бар?**

– Әгәр идеяләре булмаса, җитәкче үз урынын бушатырга тиеш. Безнең җитәкчебез Илшат Әминов шулай әйтергә ярата. Ул үзе дә, иҗади кеше буларак, әле бер яңалыкны кертергә, әле икенчесе буенча эшләп карарга омтыла. Планнарыбыз шактый. Әмма безгә, эзләнүдән туктап, бүгенгә кадәр булдырганны халыкка җиткерү өстендә эшләргә кирәк. Тәҗрибәләр вакыты узды. Бүген төпләнеп эшләү зарур. Аеруча интернет аша таралу сыйфатын яхшыртырга, радионың интернет версиясе белән дә табыш китерергә омтылырга кирәк.

**– Гөлназ белән икегез дә бер районнан. Авылга еш кайтасызмы?**

– Юк, сирәк кайтыла. Атна буе эш белән өй арасында йөреп балаларга вакыт та калмый. Ял көннәрендә авылга да чыгып китсәк, балалар үскәнен дә күрмәячәкбез.

**– Очрашып, Владимир Путинга бер сорау бирү мөмкинлегең булса, ул сорау нинди булыр иде?**

– Беләсеңме, бер татар агаеның Путинга юлланган соравына минем үземнең җавап биргәнем бар *(көлә)*. Шуңа күрә минем сорауларга ул мине канәгатьләнерлек дәрәҗәдә һәм миңа файдалы булырлык итеп җавап бирә алырмы икән? Миңа Путин алып бара торган тышкы сәясәт ошый. Украина буенча тоткан позициясе дә хуплауга лаек.





# Йорт буяумы, күз буяумы

Ремонт сүзеннән кемнәрдер куркып калырга да мөмкин. Ә миңа калса, хатын-кызларда ул шатлык хисләре генә уятадыр. Чөнки ремонт вакытында инде күптән туйдырган обой, челтәрләрне алыштыру, яңаларын алу мөмкинлеге туа.



**Данил Сәфәров**



Ремонтның тәгәл башлану көне генә бар аның. Тәгәл тәмамлану көне юк. Чөнки бетте дигәч тә мең дә бер ямау, борып кую, элеп куюлар кала. «Ремонтыгыз беттеме әле?» – дигән сорауга: «Әйе, Аллага шөкер», – дигән җавапны ишеткәнем юк минем. «Аның бетәсе юк», – диләр.

Бүген ремонтка тотынган кешегә материалы да муеннан бит аның, каһәр суккыры! Элек берни юк иде, шуңа күрә гел йорт яңартып тормадылар. Хәзер 5 мең сумлык әйбер алырга кибеткә барасың – янында 10 меңлеге кызыктырып тора. Консультант белән сөйләшкәч, 15 меңлеген күтәреп кайтып китәсең.

Ремонт индустриясе шул кадәр алга китте ки, ул үзе үк ремонтка ихтыяҗ тудыра. Ремонтны ясап кына бетерәсең, ә бу материаллар инде модада түгел икән. Хәзер инде «болай эшләмиләр» икән. Эш искелектә, сыйфатның начар булуында, пычраклыкта түгел. Бар да чип-чиста. Әмма 3-4 ел элек эшләнгән ремонт мораль (!) яктан искергән икән бит, җегетләр. Мондый өйдә ничек яшәмәк кирәк? Кеше ни әйтер?

Менә шушы урында «ремонт» дигән әкиятнең төп героена килеп җиттек, ул – кеше! Кем өчен ясыйбыз без ремонтны? Үзебез өченме? Юк. Кешегә күрсәтер өчен. Мизгелгә генә уйлап карагыз: үзебез яши торган йортыбызның интерьерын, интим куышны да кеше алдында оятка калмас өчен эшлибез. Кеше сүзеннән никадәр бәйле булуыбызны шуннан чамалагыз инде. Җәмгыятьтәге бу стереотип һәм комплекслар базар машинасын алга этүче һәм тизләтүче ягулык. Хәер, бу башка өлкәдә дә шулай. Машина, телефон, кием-салым алуда да төп этәргеч – башкалардан ким булудан курку.

«Евроремонт». Бу – индустрия уйлап чыгарган сүз. Чын мәгънәсендә ясалма сүз. Ул, һичшиксез, мәкерле максат белән уйлап чыгарылгандыр. Мәсәлән, берәр ремонтны евроремонт дип эшлиләр, ә башкасы белән чагыштырганда ул чүп икән. Ә өченче бер фатир барысыннан да «евроремонтлырак». «Евроремонт»ның нинди булганын берәү дә белми. Ул нәрсәне берәүнең дә тотып караганы юк. Әмма ул сүз бар. Ул безнең өстә очып йөри һәм кисәтә сыман: «Егетләр, әнә теге җирегез бик үк евроремонтлы булмаган, әйдә, евроларыгызны җәлләмәгез».

Индустриянең хәйләләре бихисап. Әйтик, күп кенә материаллар өстәмә җиһаз сорый: плинтус почмаклары, старт-финиш планкалары, сайдинг «баганалары» һәм башкалар. Игътибар иткәнегез бармы икән, аларның бәясе үзкыйммәтенә караганда күпкә югары. Ни өчен шулай? Чөнки без аларны сатып алырга мәҗбүр. Алар бер-берсен сорый. Менә шундый икътисади «шантаж».

Моннан берничә ел элек байлар беренчеләрдән булып пластик тәрәзәләр куйдырды. Агач рамнарны чыгарып аттылар яки алар бакчага теплицага китте. Инде бөтен кеше дә пластик тәрәзәгә күчеп бетте дигәндә, теге байлар кире агач куйдыра башламасынмы! Баксаң, пластик ул химия икән, сәламәтлек өчен зыянлы. Ә агач табигый материал, «сулый» ди. Аңлашыла ки, пластик та химиядән быел гына эшләнмәгән, агач та быел гына сулый башламаган. Бу кешеләр – индустрия корбаннары. Башта төзелеш материаллары базарында бер продукт чыга, аны шәп итеп рекламалыйлар, сату күләмен арттыралар. Аннары сатулар кимегәч, яңа (кайвакыт капма-каршы концепцияле) товар уйлап чыгарыла. Һәм кабат халыкны «сыгу» башлана.

Шулай итеп яши бирәбез. Кешегә һәр яктан һөҗүм бара. Бер яктан хәйләкәр ремонт индустриясе, икенче яктан кешенең үз эчендәге стереотип һәм комплекслар. Ә өченчегә күрше кереп җитә дә: «Обоегыз искергән бит» – дип, чигәгә «контроль ату» ясый...

## СӘФӘРОВЛАРДАН КИҢӘШ

Буяуның күләмен алдан исәпләп азапланмагыз. Буяу ул билгеле бер эчемлек сыман: күпме генә алсаң да, барыбер икенче тапкыр чабасы.

**Әдилә Сәфәрова**



Ремонт ике төрле була. Беренчесе – яңа йортта ремонт ясау, икенчесе – яшәү дәверендә ремонтны яңарту, интерьерны үзгәртү максатыннан ясала торганы. Болар арасында аерма бик зур. Беренче очракта барысын да чиста биттән башлыйсың. Монда эше дә күбрәк, чыгымнары да. Бүлмәләрне проектлау, дизайнын тәгаенләү – һәммәсе дә зур осталык таләп итә. Шуңа күрә, махсус белгечләргә мөрәҗәгать итү дә комачауламас. Дизайнерлар киңәш биргән өчен генә дә сәгатенә ким дигәндә 500 сум ала.

Әйтик, сез аны фатирыгызга яисә йортыгызга чакырдыгыз ди. Ул кайсы бүлмәгә нәрсә куярга, ничегрәк куярга һәм ничек урнаштырсаң яхшырак буласын тәфсилләп аңлата. Схемасын, дизайн-проектын ясап бирә. Төсләр, фактураларын да сайларга булыша. Шул этапта аның белән саубуллашып, калганын үзегез дә башкарып чыга аласыз.

Ремонт белән шөгыльләнергә вакытыгыз булмаса, эшчеләр чакыртып, бар эшне дизайнер һәм эшчеләр җилкәсенә йөкләргә дә мөмкин. Байлар шулай эшли дә. Ә күпчелек халык ремонтны үз көче белән эшләп чыгарга күнеккән. Аның бар кызыгы да шунда.


Ремонт ул балалар уены кебек, олыларны да сихерләп куя сыман. Кибеткә керү белән, фантазия дөньясына чумасың. Әйтик, күңелгә ошаган диван яңа диварларга туры килерме, туры килсен өчен аны нинди тукыма белән тышлаттырырга. Яисә портьер бер төсле булса яхшыракмы, әллә чуар булсамы?! Ябыштырган яңа обойлар сез теләгәнчә якты һәм матур килеп чыкмаган очракта аны ничек төзәтергә? Шундый сорауларны ачыкларга тырышып шактый кыен, дизайнерлык осталыгы таләп итә торган сорауларга дөрес һәм төгәл җавап табарга кирәк була. Шул ук вакытта әле гаилә бюджетының мөмкинлекләрен дә истән чыгармау хәерле. Шуңа күрә хатын-кыздан ремонт вакытында бик күп көч, фантазия, сабырлык таләп ителә. Иреңне иске җиһазның хәзер инде модада түгел, яңасын алырга кирәклегенә күндерү өчен бераз хәйләкәрлек тә кирәк. Бер сүз белән әйткәндә, ремонт кебек зур эшкә тотынганда яхшылап уйларга кирәк: ул сезгә чыннан да кирәкме, кайсы бүлмәгә кирәк, конкрет нәрсә алыштырасы бар һәм ул ничә сумга төшәчәк. Шушы сорауларга конкрет җаваплар тапкач кына җиң сызганып эшкә тотына аласыз.

Зәвык белән ясалган ремонт еллар үтү белән дә ялыктырмый. Андый йортка һаман әйләнеп кайтасы килеп тора. Затлы, сыйфатлы ремонт йорт хуҗаларының эчке дөньясын чагылдыручы лакмус кәгазе.

Катлаулы, чыгымлы, ләкин мавыктыргыч ремонт эшләрегезне уңышлы башкарып чыгыгыз.

# ТӨШНЕ НИЧЕК ЮРАСАҢ, ШУЛАЙ БУЛА

Элек-электән үк халык төш юрарга яраткан. Араларында махсус төш юраучылар да булган. Төшлек салу гадәте дә киң таралган. Урыс улап, татар юрап китерер дигән кебек, төш юратып без дөрес эшлибезме? Әлеге сорау белән мин Чаллы шәһәренең «Тәүбә» мәчете имам хатибы Идрис хәзрәт ГАЛӘВЕТДИНгә мөрәҗәгать иттем.



Дилбәр Гарифуллина

**– Идрис хәзрәт, төшләрне бөтен кеше дә юрый аламы?**

– Юк. Дөрес юрау өчен белем кирәк. Төшләрне белемсез килеш юрау ул табиблык белеме булмаган кешенең кулына скальпель тотып авыруга операция ясавы кебек. Гыйлемсез кеше, наданлыгы сәбәпле, төшне ялгыш юраячак. Төшне юрый белмәсәң, юрама яки инде яхшыга юра. Атның дилбегәсен кая таба тартасың, ат шул якка юнәлә, машинаның рулен кая борсаң, машина шул якка борыла. Шулай ук төш тә, әгәр син аны яхшыга юрасаң, ул чагында әйбәт була, әгәр дә төшне начарга юрасаң, яман була.

Үзем белән булган бер төшне сөйлисем килә. Моннан дүрт-биш ел элек Норлат районындагы Яңа Әмзә авылына кунакка кайткан идем. Шулай кыр-болыннарда йөргәндә чишмә кырыенда ял итим дип ятып торганда, йокыга киткәнмен. Йокыдан уянып юлымны дәвам иткәндә уң колагымның авыртканын һәм ишетми башлаганын сиздем. Колагым шуннан соң ага да башлады. Бу хәлгә чыдый алмагач, табиблар мине хастаханәгә салдылар. Әмма файдасын тапмадым. Имам кешегә ишетми торган колак белән бик авыр. Авыр булса да, өстемдәге вазифамны көчем җиткәнчә алып барырга тырыштым. Колагымның ишетмәве ике елга сузылды. Колак авырткан саен, догалар кылып, Аллаһтан ярдәм сорадым. Шулай бервакыт ястү намазыннан соң йокларга яттым һәм миңа төш керде. Имештер, мин урманнан ерак булмаган бер болында басып торам. Шулчак миңа таба дүрт елан очып килде. Бу еланнар берсе берсенә охшамаган. Берсе карандаш шикелле нәзек, ләкин бик озын. Икенчесе бик кыска, ләкин шулкадәр калын, гүя ки ул бер кисмәк. Өченчесе – кобра еланы. Дүртенчесе – әллә тузбаш, әллә гади бер елан. Аларның миңа таба очып килгәннәрен күргәч куркытым һәм алардан кулларым белән саклана башладым. Ләкин алар, минем кул араларымнан үтеп кереп, сөлек шикелле колак тирәсенә ябыштылар. Шулчак, мин куркып: «Болар бит мине чагалар», – дип уйладым. Еланнардан котылу нияте белән аларны кулым белән йолкып алып, җиргә ыргыта башладым. Алар җиргә барып төшкәндә кара балык уылдыгы кебек чәчелә башладылар. Мин шулай аларның барысын да колак һәм муен тирәсеннән әсәре беткәнче чистарттым. Шуннан соң уянып киттем. Минем башыма шул ук вакытта Фиргавеннең Муса галәйһиссәламнең таягы еланга әверелеп, 70 мең сихерчеләренең еланнарын юкка чыгарып җиңгәне, сихерне шулай юкка чыгарганы исемә төште. Аллаһы Тәгалә Коръәндә «әл-Әгъраф» сүрәсенең 104-120 нче аятьләрендә шул хакта сөйләгән. Әлеге Коръән аятьләре искә төшкәч, мин төшемне болай юрадым. Димәк, мине кемдер сихерләгән булган, ә менә бу еланнар, Муса г.с.нең таягы еланга әверелеп сихерчеләрнең бозымын юкка чыгарган шикелле, минем колагыма ясалган сихер зәхмәтен юкка чыгарачаклар. Төшемне юрап бетерүем булды, колагымдагы үзгәрешне дә сиздем. Минем колагым агудан туктаган, яхшы ишетә башлаган һәм авыртмый да иде. Төшем бик тиз тормышка ашты. Аллаһы Тәгаләгә чиксез шөкерләр булсын, бу бит – Аның ярдәме.

**– Күргән төшеңне сөйләргә ярыймы соң?**

– Бөтен кешегә дә сөйләргә ярамый! Чөнки арада төрле кешеләр бар: берәүләре көнче, икенчеләре – синең астыртын дошманнарың, өченчеләре – сине яратмаучылар. Андыйлар хәтта синең туганнарың арасында да булырга мөмкин.

**– Идрис хәзрәт, төшемә мәетләрнең нәрсә дә булса сорап кергәннәре бар, бу аларның дога өмет итүләреме?**

– Мәетләр кешенең төшенә төрле хәлдә керергә мөмкин. Күп вакытта мәетләр ризык яисә кием сорап керәләр. Ә кайчагында алар синнән берәр мохтаҗ булган әйбер сорыйлар. Бу аларның синең догаңа мохтаҗ булуларын аңлата. Алар өчен кулыңны күтәреп дога кылсаң яисә алар исеменнән берәр мохтаҗ кешегә яисә мәчет-мәдрәсәгә сәдака бирсәң, аның файдасына хәерле гамәл кылган булырсың.

**– Белүемчә, төш күрүнең бер хикмәтле ягы да бар икән: берәр катлаулы мәсьәлә алдында калып, алга таба нәрсә эшләргә кирәклеген белмәсәң, истихара намазын укырга кирәк, диләр. Имештер, әлеге намаздан соң күрелгән төш сиңа дөрес карарга килергә ярдәм итә.**

– Бу чынлап та шулай. Мисал өчен, берәү өй салырга тотынса: «Бу урын минем өчен хәерлеме, хәерсезме?» – дип уйга кала. Бу эшнең ничек хәл ителүе турында төштә бер ишарә булсын дип, Аллаһы Тәгаләдән теләк тели. Шуннан соң ул ике рәкәгать намаз укып ятып йоклый. Аллаһы Тәгалә аңа юл күрсәтә.

**– Истихара намазы ничек укыла?**

– Төннең бер вакытында тәһарәт алып, ике рәкәгать намаз кылыныр. «Фатиха»дан соң «Кәфирун» сүрәсе укылыр. Рөкүгъ һәм сәҗдә кылынып, икенче рәкәгатькә торылыр. Икенче рәкәгатьтә «Фатиха»дан соң «Ихлас» сүрәсе укылыр. Башка намазлардагы кебек намаз тәмамланыр. Сәлам биргәч, ошбу истихара догасы укылыр.

*Аллаһым! Синең белемең белән хәерне сорыймын. Кодрәтеңнән көч сорыймын һәм Синең бөек фазыйлыңны телимен. Чөнки Синең һәрнәрсәгә көчең җитәр, минем җитмәс. Син белерсең, мин белмәм. Яшерен булган эшләрне дә белерсең. Аллаһым! Бу эшнең минем динем, тормышым, бүгенге хәлем, соңгы көнем һәм киләчәгем өчен хәерле булыр дисәң, бу эшне миңа тәкъдир ит, аны эшләвемне җиңeләйт, аны миңа мөбарәк кыл. Әгәр бу эшнең динем, тормышым, бүгенге хәлем, соңгы көнем һәм киләчәгем өчен начар булыр дисәң, бу эшне миннән, мине аннан ерак тот, Аллаһым! Хәер кайда булса, миңа насыйп ит, бу эш белән мине шатландыр.*

Шуннан соң, тәһарәтле булган хәлдә йөзен кыйблага каратып ятар. Төштә ак яки яшел төс яисә күңелне күтәрүче нәрсәләр күренсә, ул эшнең хәерле булачагына, кара яки кызыл төсләр яисә күңелне төшерүче нәрсәләрне күрү ул эшнең яхшы булмаячагына дәлил дип беленер. Әгәр беренче һәм икенче көннәрдә төштә бернинди дә нәтиҗә булмаса, бу эш берничә мәртәбә эшләнер.

## Һәр мөселман сәдака бирергә тиеш

Быел фитыр сәдакасының күләме күпме һәм аны кайчанга кадәр бирергә кирәк?

Галия Кәримуллина.

Фитыр сәдакасын Рамазан ае беткәнче бирергә кирәк. Аны Ураза бәйрәменә ике-өч көн кала бирү яхшырак санала. Быел Рамазанның ахыргы көне 28 июльгә туры килә.

Фитыр сәдакасы ураза тотучының уразасы кимчелекләрдән пакьләнеп, Аллаһ каршысында тулысынча кабул ителүен өмет итеп бирелә торган сәдакадыр. Гаилә башлыгы хатыны һәм балалары өчен дип сәдака бирә. Рамазан башланыр алдыннан гына бер бала туса, аның өчен дә фитыр сәдакасы бирү тиешле. Әгәр балалары үзләре эшләп акча таба яки аерым, гаилә булып яши икән, алар фитыр сәдакасын үзләре түли. Быел фитыр сәдакасының күләме 50 сум дип билгеләнде. Сәдака фәкыйрьләргә һәм мескеннәргә бирелә.

## Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк

Ислам дөньясында айлар арасында – Рамазан ае, көннәр арасында – җомга көне, кичләр арасында Кадер кичәсе иң мөбарәк вә иң мөкатдәсе булараК кабул ителгән. Бу көнне Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (с.г.в.) Коръән иңдерелә башлаган. Кадер кичәсенең Рамазан аенда икәнлеген белсәк тә, аның төгәл көне билгеләнмәгән. Бер хәдисендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): «Кадер кичен Рамазанның соңгы ун көне арасыннан, бигрәк тә так санлы кичләреннән эзләгез», – дигән. Әмма шунысы билгеле: Кадер кичәсе таңында кояш ап-ак булып чыга, көне дә аяз, тыныч-җилсез була.

Хәдисләрдән аңлашылганча, Кадер кичәсендә кешенең алдагы бер еллык тәкъдире языла. Шуңа да адәм баласы, үзенә бер еллык күркәм бер тәкъдир иңсен, елы бәла-казаларсыз үтсен өчен, бу төнгә игътибарлы булырга, төнен дога кылып, Коръән укып, теләкләр теләп уздырырга тиеш.

Туфан Миңнуллин

# САЙЛАУ

## (Математик хикәя)



Сайлаулар була дигәч, һәм ул сайлауларга бик нык әзерләнергә кушылгач, колхоз рәисе Хисмәтов авылның иң күпне күрүче, кирәгеннән артыгын белүче бәйләнчек бер кешесен – Шәйхетдинне чакыртып алды:

– Сайлаулар буласын беләсеңме, Шәйхетдин абый? – диде.

– Беләм, кәнишне, – диде Шәйхетдин.

– Ничек соң? Сайлауга барасыңмы?

– Юк! – дип кистереп әйтте Шәйхетдин.

– Ни өчен? – дип төпченде Хисмәтов.

– Чөнки дә ул сайлау түгел.

– Ни өчен инде түгел?

– Үзең уйлап кара, иптәш Хисмәтов, нәрсә дип әйтелгән анда? Әгәр дә 25 пратсинт сайлаучы килсә, сайлау булды дип санала, диелгән. Примиргә безнең авылны алыйк. 48 сайлаучы бар бездә. Шуның 50 пратсинты барды ди. Күпме була? 48не 2гә бүләбез – 24 буламы? Шул 24нең 50 пратсинты күпме чыга? Нәкъ 12 чыга. Дипутатны 48 кешенең 12се сайлагач, сайланган буламы? Шул 12 кеше сайлаган дипутат 48 кеше өчен сөйлиячәкме? Дөрес әйтәмме?

– Әйтүен дөрес әйтәсең, Шәйхетдин абзый. Менә әгәр дә мин әйтсәм, сайлауга бар, Шәйхетдин абый, дисәм?

– Син әйтсәң дә бармыйм, иптәш Хисмәтов. Димакратия бар, дип әйтәләр бит. Дөрес әйтәмме?

– Бик дөрес әйтәсең, Шәйхетдин абый, – дип, рәис Хисмәтов Шәйхетдиннең иңнәреннән чәбәкләп алды. – Син инде, Шәйхетдин абый, бу әйткәннәреңне фермада эшләүче авылдашларыңа да әйт.

– Әйтәбез аны, иптәш Хисмәтов, – дип, Шәйхетдин чыгып китәргә җыенган иде, рәис туктап торырга кушкач, туктады.

– Мал-туарыңа курмы җитәрлекме соң? – дип кызыксынды рәис. – Сыер бераүме әле синең?

– Икене калдырган идем. Бер тана да бар. Үгезне дә кышлатырга иде исәп.

– Сарыклар да бардыр әле?

– Алар да бар. Унлап булыр.

– Курмың җитмәсә, тартынып торма, Шәйхетдин абый, кил, – дип озатып калды Шәйхетдинне рәис.

Озакламый тагын Шәйхетдинне чакырды. Шәйхетдин үзенең «пратсинтлар»ын санап чыкты.

– Сайлауга бармыйм... Дөрес әйтәмме? – диде.

– Әйтүен дөрес әйтәсең, Шәйхетдин абый, – диде Хисмәтов, – менә әгәр дә мин әйтсәм, сайлауга бар, Шәйхетдин абый, дисәм?

– Син әйтсәң дә бармыйм, иптәш Хисмәтов. Димакратия бар, дип әйтәләр бит. Дөрес әйтәмме?

– Бик дөрес әйтәсең, Шәйхетдин абый, – диде рәис Хисмәтов. – Син дөрес әйткәнеңне бүтәннәргә дә әйт.

– Әйтәбез аны, – дип, Шәйхетдин чыгарга борылган иде, Хисмәтов аны туктатты.

– Курмы якларың ничек соң? – дип сорады рәис.

– Тартып-сузып җиткерергә инде исәп, – диде Шәйхетдин.

– Тәк... ике сыер, бер тана, бер үгез, ун баш сарык, – дип саный башлады Хисмәтов, – кара исәп белән генә алты олау печән, сигез олау салам, егерме капчык фураж кирәк. Колхоздан күпме яздырып алдың соң, Шәйхетдин абый?

– Алуын инде... анысын, бирделәр инде шунда, – дип тотлыкты Шәйхетдин.

